Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 10 (1426) 17 март 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

2

Себер татарларын аерып чыгарып, үзәктә милләт тамырына тагын бер балта чабарга маташалар.

12

Чиләбе өлкәсендәге Караболак, Мөслим авыллары кичергән фаҗигаләр дә илдә халкыбызга мөнәсәбәтне күрергә мөмкинлек бирә.


17

Бөек Тукай шигырьләрендә тыныш билгеләре мәсьәләсе дә игътибарда булырга тиеш.

Сәхнә аңа һәрчак тәхет булды Хан чакта да, шагыйрь чакта да!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Легендар җырчы, Татарстанның халык артисты Флера Сөләймановага Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе тапшырылды.
- «Казан утлары» китапханәсе сериясеннән унсигезенче басма – язучы Рәдиф Сәгъдинең «Бер гаилә сурәте» китабы дөнья күрде.
- Рәссам Роман Сәйфуллин иҗат иткән Муса Гәрәев портреты Башкортстанның Хәрби Дан музеена бүләк ителде.
- Мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен «Татар халкының традицион костюмнары» сериясендә буягыч китаплар әзерләнде.
- Ваһапов фонды уздыра торган «Шәрык базары» халыкара милли мәдәниятләр фестивале «Президентның мәдәни башлангычлар фонды»ның 14,2 миллион сум грантын откан.
- «Адымнар – белемгә һәм татулыкка юл» күп телле белем бирү комплексының рус теле һәм әдәбияты мөгаллимәсе Екатерина Лисина Татарстанда 2023 елның «Ел укытучысы» дип танылды.
- Уфаның «Мирас» җыр һәм бию ансамбле «Хәзинә» программасы белән Россия төбәкләре буйлап гастрольләрен Казанда башлады.
- Татарстан Дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең Болгариядә гастрольләре узды.
- Казан тел галимнәре Удмуртиянең Халыклар дуслыгы йортында татар һәм удмурт телләренә өйрәтә торган үзөйрәткеч китаплар тәкъдим итте.

Мәдәни җомга
17 март
№10, 2023

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Искәндәр ИЗМАЙЛОВ, тарихчы галим:

«Тарихи романга фэнтези жанры кушылуына килгәндә, тарихи романның чикләре киң, резина кебек сузыла, әмма без теләгәнчә үк түгел. Без Казан ханлыгы турында, Иван Грозный гаскәрен куып җибәреп мөстәкыйльлеген саклап калган, дип яза алмыйбыз».

СЫНАМЫШЛАР

18 мартта кар яуса, чикләвек һәм карабодай уңар ● 19 мартта җылы булса – ашлык, кар яуса – чикләвек уңар ● Мартта җирдәге салам карга эреп керсә, бер айдан кар китәр ● Мартта яуган кар бакча җимешенә бик ярар ● Язын кар кояш каравы белән эресә, бодай яхшы булыр ● Әгәр карга көньяктан ябыгып кайтса, ашлык уңар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 56 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 50 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **11 сәгать 54 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **24 мартта 12 сәгать 26 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

17 март – балетмейстер, балет артисты Рудольф Хәмит улы Нуриевнең тууына 85 ел (1938–1993);
– тел галиме, педагогика фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Чулпан Мөхәррәм кызы Харисовага 70 яшь (1953);
– эстрада җырчысы, Татарстанның атказанган артисты Булат Җәүдәт улы Нигъмәтуллинга 50 яшь (1973).
18 март – шагыйрә Фәйрүзә Вәгыйзь кызы Исмәгыйлевага 60 яшь (1963).
20 март – баянчы, Башкортстанның халык артисты Халит Шәех улы Фатыйховка 65 яшь (1958).
22 март – язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәшит Гариф улы Гарифнең (Гарипов) тууына 90 ел (1933–2006).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(15-21 март)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 25 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Фәүзия БӘЙРӘМОВА

Себер татарларын кем аера?

Бу көннәрдә интернетта шомлы хәбәрләр таралды – имеш, себер татарларын милләтебездән аерып алып, аерым халык, аерым тел дип игълан иткәннәр! Ә татар халкы, Себердә һәм Казанда яшәүче милләттәшләребез, галимнәр моны белми дә калган икән! Милләтнең бөтенлегенә каршы бу мәкерле эшне, грандиоз афераны кем башкарып чыга алган соң, Татарстан нигә моны иң соңыннан гына белгән?

Матбугаттан күренгәнчә, 21 февральдә Мәскәүдә, Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты уздырган видеоконференциядә, академик Александр Кибрик: «Мы берём на себя обязательство решить, сибирскотатарский язык и татарский язык – это один язык или не один, а два языка. Институт языкознания РАН признал существования сибирского татарского языка. Аргументы за существование отдельного сибирскотатарского языка есть безусловно», – дип нәтиҗә ясый. Ягъни казан һәм себер татарларының теле – икесе ике аерым тел дип, Мәскәү галимнәре тарафыннан себер татарларының җирле сөйләм теле, ягъни шивә-диалектлары аерым мөстәкыйль тел дип танылган, ул гомумтатар әдәби тел составыннан чыгарылган. Бу, үз чиратында, себер татарлары аерым милләт, дигәнне, бердәм татар милләте составыннан чыгарыла икәнен аңлата.

«Бу мәкерле эшнең артында кем тора?», дигән сорауга җавапны тиз таптык, алар үзләре үк таныды – татар милләтенең бөтенлегенә каршы бу афераның артында Мәскәү, Россия Фәннәр академиясе галимнәре тора булып чыкты. Ә аларга Себердә яшәүче урыс телле бер төркем татарлар ярдәм иткән. Видеоконференциядән күренгәнчә, Себердән ирле-хатынлы Юрий Квашнин һәм Гөлсифа Бакиева, авызларыннан ут чәчеп, «Татар милләте юк, ул – Советлар Союзында уйлап чыгарылган милләт!», дип бәхәсләшә, ә Мәскәү галимнәре шуның белән ризалаша, моңа каршы килми. Себер татарлары темасын үзләренең ипие иткән, әмма шул ук вакытта, «Татар дигән милләт юк ул, аны советлар гына уйлап тапкан!», дигән бу пар турыдан-туры милләткә каршы эшли! Аларга себер татары да, казан татары да кирәк түгел! Гөлсифа Бакиеваның Тубылдагы духовная семинариядә укытып йөрүен, православие динен таратуга уңайлы булсын өчен, булачак попларга магистратурада «себертатар теле»н өйрәтүен, Библиянең бер өлешен татарчага тәрҗемә итүен, аны милләттәшләребезгә бушка таратып йөрүен дә әйтсәк, бу хатынның кемгә эшләгәне ачык аңлашыла. Аларга тел әрәм итмик.

Инде, «Без себер татарлары белән бер милләтме, әллә аерым ике халыкмы?» – дигән сорауга, тарихчы һәм язучы буларак җавабым – БЕЗ БЕР МИЛЛӘТ! Моның дәлиле – татар тарихы һәм милләт тормышы үзе. Алтайдан – Урал тауларынача, Котыптан – кыпчак далаларына кадәр таралып яшәгән милләттәшләрем янында күп тапкырлар булып, аларны өйрәнеп, себер татарлары турында дистәләгән фәнни-популяр хезмәтләр, тарихи романнар язган кеше буларак, минем болай дип әйтергә хакым бар. Безне, себер һәм казан татарларын, уртак бөек Татар Тарихы берләштерә – без барыбыз да Алтын Урда дәүләте варислары. Без Казан һәм Себер ханлыклары тарихында да ханнар алмашып, авыр вакытта бер-беребезгә ярдәмгә килеп, кыз биреп, кыз алып яшәдек. 1552 елда Казанны яклап сугышучылар арасында Себер яугирләре дә бар иде, Себер өстенә бәла килгәч, казан татарлары да аның өчен утка керде...

Безне, казан һәм себер татарларын, изге ислам дине берләштерә – Себергә ислам гыйлеме Бохара һәм Казан аша килгән, Казан ханлыгы җимерелгәч, исән калган галимнәребез, мөселманнар Себергә күчкән, кара урманнарда ислам нурын тараткан. Патша һәм Сталин чорында Себергә сөрелгән меңләгән дин әһеле, татар зыялылары да биредә мөселманлыкны саклаган, шунда тамыр җибәреп, җирле халык арасында дин тараткан. Безне, себер һәм казан татарларын, әдәби татар теле – Китап теле берләштерә! Дин әһелләре, галимнәр белән бергә Себергә Китап сүзе килгән, Кол Гали, Сәйф Сараи, Мәрҗани, Риза Фәхретдинов, Тукай, Такташ, Җәлил әсәрләре килгән. Себердән исә безгә антик эпосларга тиң мең еллык дастаннар, борынгы төрки мәдәният килгән, танылган дин әһеле һәм милли сәясәтче Габдрәшит Ибраһим, галимнәр Фоат Вәлиев, Диләрә Тумашева, Флора Урманче, Фатыйх Урманчеев һ.б. акыл иярләре килгән, Булат Сөләйманов һәм Якуб Зәнкиевләрнең әдәби татар телендәге китаплары Казанда басылган. Болар барысы да уртак байлык, уртак мирас бит, ничек шушыларны бүлгәләмәк кирәк?!

Мин себер татарларының тарихын һәм мәдәниятен югары бәялим, минем өчен ул – төпсез хәзинә, ачылмаган дөнья! Заманында Бөек Татария, Туран Иле, Скифия дип аталган төрки-татар цивилизациясе! Җиһангир патшалар Атилла һәм Чыңгыз ханнарның, Күчем ханның Ана Ватаны, ә бүгенге себер татарлары – аларның хаклы дәвамчылары. Нинди кырыс шартларда да, зәмһәрир салкыннарда, кара урманнарда, сазлык араларында яшәп, алар Кеше булып калды, татарлыгын онытмады. Татар милләтенең нигезе – матрицасы да нәкъ Себердә! Танылган тарихчы Миллер юкка гына татарларны Себернең төп халкы, димәгән бит инде. «Главнейшим народом Сибири являются татары, которые живут в южных местностях по рекам Тоболу, Иртышу, Оби, Томи и Енисею и лежащих между ними степях. История татарского народа относит начало его к таким далеким временам, какими не может похвалиться ни один из европейских народов». (Г.Ф.Миллер. История Сибири. – Москва, 1999, стр.166.)

Мин казан татарларының да тарихын һәм мәдәниятен бик югары бәялим, ул – Болгар-Биләрләрдән килгән мең еллык ислам мәдәнияте, мәгърифәт, интеллектуаль көч, дәүләтчелек традициясе. Без – чын мәгънәсендә, Китапны саклап калган халык, янәшәдәге кардәш милләтләргә хәреф таныткан, Аллаһ сүзен җиткергән зур халык! Казан татарлары дәүләтләрен югалтканда да, иманнарын югалтмады, кемлекләрен онытмады, телне һәм динне бирмәде, дөньяга үч тотмады, нинди шартларда да, Кеше булып, Татар булып калды!

Инде бәхәс чыганагы булган тел турында да әйтим. Татар теле турында. Әйе, себер татарларында аларга гына хас тел үзенчәлекләре бар, әмма бу аерым тел дигәнне аңлатмый, ә аңа гаять борынгы катламнарның тәэсирен күрсәтә. Себер татарларының сөйләм телендә борынгы төркиләрнең бөтен төсмер-билгеләре бар – анда татар-уйгыр, иштәк-нугай, кыргыз-кайсак-казах, үзбәк-чагатай-төрекмән сөйләмнәре чагылыш тапкан. Әйе, себер татарларының сөйләм теле – ул борынгы дастаннар теле, Алыплар һәм Түләк-Сусылулар, Карьят батырлар һәм Җик Мәргәннәр теле, Кузы Көрпә белән Баян Сылулар, Идегәйләр теле... Бу да – уртак тел, урак әдәби мирас, милли хәзинә бит, инде шуны да бүлешикме?!

Без, татарлар, Сак-Сок кошлары кебек, язмыш тарафыннан Урал тауларының ике ягында аерылып калганбыз, әмма рухларыбыз белән аерылмаганбыз. Себер татарларында булган көчле милли рух, казан татарларында булган акыл көче безне бер милләт итеп берләштергән һәм саклап калган. Безнең тарихи бердәмлеккә кайбер тел аерымлыклары да комачау итә алмаган, чөнки андый гына аерымлыклар авыл белән авыл арасында да бар. Әйе, сөйләм теле белән әдәби тел гасырлар буе янәшә яшәгән, әмма аерылмаган, чөнки бу тән белән җанның аерылуы кебек булыр иде. Мең еллар буе асылташтай чарланган, энҗе-мәрҗәндәй шомартылган, йолдыз кебек нур чәчкән әдәби татар теленнән баш тарту – шушы нигъмәттән, уртак мирастан, үткәнеңнән һәм киләчәгеңнән баш тарту булыр иде!

Себер татарларын зур татар милләте составыннан аерып алу – аны замана авырлыклары алдында япа-ялгыз калдырачак. Бу мәкерле проектны уйлап табучылар һәм тормышка ашыручылар себер татарларына тел дә, дәүләт тә бирмәячәк, аларны бердәм татар милләтенә каршы файдаланачак һәм тарих чүплегенә чыгарып ташлаячак. Мин ышанам, себер татарлары бу агулы кармакка капмас, бер төркем коткычы авантюристлар алдавына ышанып, уртак милләтебездән, телебездән, тарихыбыздан ваз кичмәс, кайда яшәсә дә, БӨЕК ТАТАР булып калыр! Без – себер һәм казан татарлары, бер кошның ике канаты кебек, бергә булганда гына, яңадан күкләргә күтәрелербез, кешелек тарихында үз лаеклы урыныбызны алырбыз, ин ша Аллаһ!

Бердәнбер һәм универсаль чишелеш

«Өметсез – шайтан», ди мәкаль. Ике генә сүз, әмма элгәреләребез тарафыннан аларга нинди тирән әхтәлек вә фәлсәфи мәгънә салынган! Хактан да шулай: кешене иң элек өмет һәм киләчәккә ышаныч яшәтә. Соңгылары анда инану аша формалаша һәм ныгый. Ә илаһи көчкә инану сыйфаты адәми затка тумыштан (яралтылыштан) ук та бирелә. Шуңа күрә инсаннарга өмет-хыяллар вә киләчәккә ышаныч белән яшәү хас. Шайтан исә дини мифологиядә Җиргә явызлык таратучы, кешеләрне юлдан яздыручы яман зат, иблис токымлы мәлгунь итеп бирелә. Оҗмахтан сөрелгәндә ләгънәт камыты кидерелгән зат буларак, аның киләчәге берничек тә өметле була алмый. Тик, ни аяныч, Җирдә әлегә шайтани рух тантана итә. Шуңа анда купкан геосәяси өермә дә бүген шайтан туен хәтерләтә. Аның нигезендә адәми затның рухи яктан иблис вәсвәсәсенә бирелүе һәм яшәештә илаһият кануннарыннан читләшүе ята. Димәк, инсаниятнең төп проблемасы бүген рухият өлкәсендә ята булып чыга. Шулай булгач, аннан арыну өчен дә кешеләрнең иң элек иманга килүе һәм илаһи канунлар буенча (киң мәгънәдә) яши башлавы лязем. Шунысы да бик мөһим, бүгенге фаҗигале вәзгыятьтә кешелек дөньясы өчен инде бу – бердәнбер һәм универсаль чишелеш.

Соңгы тезисның хаклыгына инану өчен, зур сәясәттә бүгенге хәтәр хәлләргә китергән геосәяси вә идеологик үлчәмнәрне инде метасәяси (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте) һәм фәлсәфи фикер калыпларына да салып карыйк. Мәгълүмдер, глобаль сәяси каршы тору бүген идеологик яктан «автократия-демократия көрәше» шәкелендә барса, геосәяси планда ул «берполярлы дөньямы, күпполярлы яңа дөньяви тәртипме» дигән дилеммага кайтып кала (шул нигездә капма-каршы ике коалиция формалашып килә). Ә хәзер адәми затның, ниһаять иманга килеп, илаһият кануннары нигезендә яши башлавын күз алдына китерик (дөрес, күпләр моны әлегә ниндидер идеалистлар башында туган фантазия дип кенә кабул итә, гәрчә кешелек өчен ул тәкъдир тактасында язылган булса да. Ә сайлау мөмкинлеге аның бүген зур түгел: йә тәкъдир кушканча яшисең, йә юк буласың). Аңлашыла булыр, илаһият кануннары буенча яшәү аның бүген хәл итеп булмый торган күп кенә проблемаларының үзеннән-үзе юкка чыгуына китерәчәк. Геосәяси үлчәмдә бәяләгәндә, әлбәттә, ул берполярлы дөнья булачак. Әмма, аерма шунда ки, хакимлек анда иблис токымы тарафыннан түгел, ә илаһият кануннары нигезендә, Аллаһ кушканча урнаштырылачак.

Әйтелгәннәрне инде конкрет мисалларда да карыйк. Шул ук «автократия-демократия көрәше»н генә алыйк. Илаһият кануннары бөтен кешелек дөньясы өчен дә уртак, шуңа анда геосәяси бүленеш булмаячак. Ә инде хокукый, милли, дини, икътисади, иҗтимагый, социаль, сәяси һ.б. багланышлар (димәк, халыкара вә дәүләтара мөнәсәбәтләр дә) илаһият кануннары нигезендә (ягъни гаделлек принципларында) һәм метасәяси кысаларда формалаштырылачак. Илаһи чишелешнең универсальлеген аңлау өчен кайбер четерекле темаларга да тукталыйк. Мисалга, сексуаль азчылык проблемалары, яисә бер җенесле гаилә кору кебек кыргыйлыкны гына алыйк. Асылда болар һәммәсе дә – иблис токымы куерта торган ясалма проблемалар. Максаты Җирдә халык санын кимету. Автократия аны спекулятив максатларда да куллана. Тик алар һәммәсе дә илаһият кануннарына каршы килә, ягъни бидгать гамәлләр булып тора. Шуны ук геннарны модификацияләү яисә ясалма интеллект тудыру кебек хәтәр гамәлләргә карата да әйтеп булыр иде. Чөнки алары да – фәкать Җәнабе Хак ихтыярындагы гамәлләр.

Күренә ки, бүгенге мең бәлале яшәешкә бер генә универсаль вә барлык халыкларның да күңеленә хуш килә торган альтернатива бар, ул – илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү. Әмма бәндәләрнең бу тарафка атлыгып торганлыгы әлегә бик сизелми. Киресенчә, иблис токымы яңа дөньяви тәртипне дә, үз геосәяси максатларына туры китереп, үзенчә кору нияте белән яна. Көнбатыш һәм Россиянең, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итүен дә исәпкә алсак, вакыйгалар сөреше отыры кабат шул тарафка борылырга мөмкин. Тик геосәяси нигездә каршы торучы якларның үзләренә дә житди үзгәрергә туры киләчәк. Эш иң элек БМОны реформалау, аны яңа принципларда үзгәртеп корудан башланыр кебек. Бу җәһәттән зур җаваплылык БМО Генераль Ассамблеясе эшчәнлегенә, анда өстенлек иткән мәсләк тарафдарларына төшә. Кешелек дөньясының бүген глобаль упкын алдында торуын да исәпкә алганда, аңлашыла булыр, БМО нигезенә бүген илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү принцибы салынуы зарур. Димәк, аның инде дөнья җәмәгатьчелеге өчен дә төп хәрәкәт юнәлешенә әйләнүе лязем. Шуңа күрә зур җаваплылык тарихның географик күчәре саналган Урталык җирләрендә яшәүче халыкларга, шул исәптән ул тарихта тирән эз калдырган татар халкына да төшә.

Фоат УРАЗАЙ.

Тукай бүләген дәгъвалаучылар

Татарстан Рәисе каршындагы комиссия тарафыннан 2023 елда Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә 13 кандидат тәкъдим ителгән.

Әдәбият өлкәсендә:

«Яңу дәверләрендә» һәм «Вөҗдан үре – йөрәк түре» китаплары өчен Флера Гыйззәтуллина;

«Су буенда учак яна» китабы өчен Наил Касыймов;

«Аучы җыры», «Чоңгыл», «Иман капка ачканда», «Себерем – үз җирем» җыентыклары өчен Себердән татар шагыйре Шәүкәт Гаделша.

Театр өлкәсендә:

«Адәмнәр» спектакле белән «Әкият» курчак театрының иҗат коллективы (Илгиз Зәйниев, Сергей Рябинин, Эльмир Низамов, Дилүс Хуҗәхмәтов, Альбина Шаһалиева);

Чаллы театрының «Абага алмасы ачы була» спектакленең иҗат төркеме (Фаил Ибраһимов, Рафил Сәгъдуллин, Равил Сабиров);

Кинематография өлкәсендә:

«Күктау», «Байгал», «Исәнмесез!?» фильмнары өчен Илдар Ягъфәров белән Мансур Гыйләҗев;

«Заступница», «Осанна», «Святитель» документаль-нәфис трилогия өчен Алексей Барыкин.

Музыка сәнгате өлкәсендә:

«Халкым моңнары», «Из коллекции фольклориста: татарско-мишарские песни» «В мире татарской музыки», «Ярулиннарның туган җир җырлары», «Татарская музыка: история и современность», «Нурлат районының татар җырлары», «Очерки по татарской музыке» хезмәтләре өчен Земфира Сәйдәшева;

Татарстан Республикасы халыкларының җыр-инструменталь традицияләренә керткән өлеше өчен Геннадий Макаров.

Сынлы сәнгать өлкәсендә:

Милли темага багышланган декоратив паннолар өчен Наилә Кумысникова;

Татарстанга багышланган сәнгати фоторәсемнәр өчен Фәрит Гобәев;

Архитектура өлкәсендә:

Түбән Кама шәһәрендәге милли архитектура әсәрләре өчен Фирдәвес Ханов;

Татарстанның агач архитектурасына багышланган жиде томлык альбомы өчен Равил Айдаров тәкъдим ителгән.

«Урал сандугачы»н барладылар

Екатеринбургта инструменталь музыка сәнгате һәм татар җырын башкаручыларның «Урал сандугачы» дип аталган XVI төбәкара бәйгесе узды.

Чараны Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеге, «Свердловск өлкәсе татарлары (Урал татарлары) конгрессы» төбәк иҗтимагый оешмасы һәм Свердловск өлкәсенең дәүләт Халык иҗаты сарае оештырды. Бәйгене үткәрүдә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Татарстан һәм Свердловск өлкәсе мәдәният министрлыклары ярдәм күрсәтте.

Конкурста Свердловск, Курган, Чиләбе, Төмән, Оренбург, Новосибирск өлкәләреннән, Татарстан, Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан, Пермь краеннан 200 дән артык талантлы башкаручы катнашты.

Чыгышларга Татарстанның халык артистлары Зәйнәп Фәрхетдинова, Вил Усманов; Татарстанның атказанган артисты, Казан дәүләт мәдәният институтының музыка сәнгате кафедрасы мөдире Наил Сәгъдиев, җырчылар Зәринә Хәсәншина, Сөмбел Билалова һ.б.лардан гыйбарәт мәртәбәле жюри бәя бирде. Беренче дәрәҗә лауреатлар арасында Чаллы, Тубыл, Екатеринбург шәһәрләре, Пермь краеның Барда районы вәкилләре бар. Гран-при Удмурт Республикасының Ижау шәһәрендәге «Асылъяр» дип аталган татар музыкасы, җыр һәм бию ансамбленә тапшырылды.

Кайгыда да, шатлыкта да бергә!

Евразия Язучылар берлегенең «Кардәш каләмнәр» журналының март саны дөнья күрде. Ул тулысынча Төркиядәге зур фаҗига, гасыр һәлакәтенә багышлана.

Журнал Евразия Язучылар берлеге рәисе Якуп Өмәруглының кереш сүзе белән ачыла. Якуп әфәнде үзенең язмасында әлеге фаҗиганең бөтен төрки дөньяны никадәр тетрәндерүе, һәркем дә төрек халкына ярдәм кулы сузарга омтылуы, бу хәсрәтне үзләренеке кебек кабул итүләре хакында тәэсирләнеп яза.

Журналда урын алган Төркия, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Казахстан, Үзбәкстан, Әфганстан, Ирак, Дагстан, Косово, Македония, Башкортстан, Кырым, уйгур, гагауз шагыйрьләренең йөрәк тибешенә Татарстан шагыйрьләре Сания Әхмәтҗанова белән Рәмис Аймәтнең дә җан авазы килеп кушыла. Журналда шигырьләр белән беррәттән әлеге вакыйга белән бәйле рәвештә иҗат ителгән хикәяләр дә урын алган.

Шигырьләрне Төркиянең Бартын университеты укытучысы Алып Эрән Демиркая белән Төркиядә яшәп, андагы татарлар һәм төрки халыклар тормышын даими яктыртып торучы милләттәшебез, журналист Рушания Алтай тәрҗемә иткән.

Навигатор татарча сөйли

«Яндекс Карты»да татар телендә автомобиль навигациясе барлыкка килде. Хәзерге вакытта анда 200 дән артык җөмлә-гыйбарә яздырылган.

Навигатор «АИГЕЛ» электрон хип-хоп дуэты җырчысы Айгөл Гайсина тавышы белән сөйләшә. Кайбер җөмләләрдә ул татар мәдәнияте элементлары, шул исәптән, уеннар, милли ризыклар һәм фольклор персонажлары турында телгә ала. Мисал өчен, тукталышка якынлашканда, Айгөл ял итеп алырга һәм өчпочмак белән чәй эчәргә тәкъдим итә, ә машина йөртүче маршруттан читкә тайпылган очракта, аны урманда яши торган Шүрәле юлдан яздырырга мөмкинлеген әйтә.

Татар телен сайлау өчен, «Яндекс Карты» сервисының «настройка» бүлегенә керергә, «звуки и оповещения» бүлегенең «язык аннотаций» дигән өлешенә басарга кирәк.

1 нче биттә – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ринат Таҗетдинов Г.Камал театрында 85 яшен билгеләп үтү кичәсендә. С. Камалетдинов фотосы. «Татар-информ».

Пермь крае – татар төбәге

Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институтында «История татарских деревень Октябрьского городского округа Пермского края» дигән китапны тәкъдим иттеләр. Аның автор-төзүчесе һәм фәнни редакторы – тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаев.

Хезмәт – Пермь якларында татарларның, алар гомер кичергән авылбистәләрнең килеп чыгышы тарихын өйрәнүнең беренче омтылышы. Китапта төбәктә яшәгән милләттәшләребезнең этник үзенчәлеге, күчеш процесслары күп гасырлар элек булган вакыйгаларга бәйләп аңлатыла һәм төрле чыганаклар ярдәмендә округның 23 авылы тарихы бәян ителә, аларның нигезләнү вакыты төрле материаллар белән дәлилләнә. Хезмәттә шулай ук авылларның үткәннәре ил тарихындагы күп кенә вакыйгаларга бәйләп алып барыла. Әйтик, колхозлашу еллары, репрессияләр, мәчетләр язмышы, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, тыл хезмәтчәннәре һ.б. китапта әһәмиятле урын алып тора.

Галим Пермь якларындагы татар авылларын өйрәнү белән 1990 нчы еллардан башлап шөгыльләнгән һәм әһәмиятле документлар тапкан. Пермь татарларының 1963 нче елгы писцовый кенәгә язмалары һ.б. архив документлары моңарчы аз билгеле булган мәгълүматларны тәгаенләргә ярдәм иткән.

Ф.Ислаев Пермь краеның татар халкы өчен чит җирләр булмавын искәртә. «Бирегә татарларның беренче дулкыны Идел Болгарстаны заманнарында ук күчеп утырган. Алар су юлы белән килеп, яңа җирләрне үзләштергәннәр. Руслар бу якларга күчеп килгән вакытта, хәзерге Пермь крае биләмәләрендә иң яхшы чәчүлек җирләр татарларныкы булган», – диде галим. Казанның алынуы Пермь татарлары яшәешен дә үзгәрткән. Казан ханлыгының мөстәкыйльлеге бетү Россия дәүләтенә Урал буйларына да актив үтеп керергә мөмкинлек биргән. Патша хакимияте яңа җирләрне үзләштергәндә, көньяк биләмәләрдә яшәгән татарлар белән очрашкан. Нәтиҗәдә Пермь якларына үтеп керү акрынайган.

Басма ике өлештән тора. Аның икенче бүлегендә татар авыллары турында мәкаләләр тупланган. Аларны авторлар коллективы әзерләгән. Бу материаллар аша авылларның, барлыкка килү вакытыннан алып, хәзерге заманга хәтле булган мөһим вакыйгалары белән танышырга мөмкин.

Сөембикә КАШАПОВА.

Халык театрлары бәйгесе

Бишбүләк районында РСФСРның атказанган артисты Тимербулат Имашевның тууына 115 ел тулуга багышлап фестиваль оештырылды. Анда Башкортстанның 32 районыннан 62 халык театры, Пермь, Оренбург һәм Татарстан театрлары катнашты. Тәтешле районының «Илһам» халык татар театры фестивальдә Батулланың «Кичер мине, әнкәй» әсәрен сәхнәләштергән. Төп рольне башкарган Гөлшат Шабутдинова «Иң яхшы һәвәскәр артист» номинациясендә II урынга, Миргали ролен башкарган Арлиан Габделхаков исә махсус призга ия булды. «Илһам» театры принтер белән бүләкләнде.

«Замандаш» халык татар театры (Краснокама районы) режиссеры Редик Ганиев «Авыл һәвәскәр театрының иң яхшы җитәкчесе» номинациясендә I дәрәҗә лауреат булды.

Шушы ук номинациядә Татарстанның Балык Бистәсе районы халык театры режиссеры Илназ Шакиров III дәрәҗә лауреат исемен алды.

«Иң яхшы авыл театры» номинациясендә Пермь крае Барда районының халык татар театры җиңү яулады. Бу коллектив Хәбир Ибраһимның «Ялгыз каен күзе» спектакле белән тамашачы мәхәббәте махсус призына ия булды. Бу номинация быел беренче мәртәбә куелды, ул Культура.рф порталында трансляцияләнгән караулар саныннан чыгып билгеләнә. «Ялгыз каен күзе» спектаклен 3682 тапкыр караганнар.

Г. ХӨҖҖӘТОВА.

Мохтарият тә берләшү юлында

Болгарда Татар федераль милли-мәдәни автономиясе советы утырышы узды. Җыенга Россиянең 43 төбәгеннән 97 делегат килде.

Автономия 25 ел дәвамында эшчәнлек алып бара. Аның составына 38 региональ һәм 7 җирле автономия керә. Утырыш барышында составка тагын бер оешма – Хабаровск милли-мәдәни автономиясе – өстәлде.

Автономиянең рәисе Илдар Гыйльметдинов әйтүенчә, 25 ел элек нигез салынган оешма бүген дә актив эшли. «Әйтергә кирәк, без Россия күләмендә иң зур милли оешмаларның берсе һәм шушы вакыт дәвамында гел үсеш юнәлешендә бардык. Автономия барлыкка килгәндә дистәдән артык оешма керә иде, бүген аларның саны 50 гә якын. Бу – төбәкләрдәге татарларның активлыгын, татар милләтен үстерүгә көч куярга әзерлеген дәлилли», – диде ул.

Татар федераль милли-мәдәни автономиясе съездында Луганск Халык Республикасы делегатлары да катнашты.

Милли-мәдәни автономиянең беренче рәисе 1998-2002 елларда Индус Таһиров булды, 2002-2007 елларда оешманы Римзил Вәлиев җитәкләде. Илдар Гыйльметдинов 2007 елдан бүгенге көнгә кадәр рәис булып тора.

Башкала хәбәрләре

Мәскәүнең Татар мәдәнияте үзәгендә Татарстанның Россиядәге Вәкаләтле вәкиллеге инициативасы белән Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, драматург һәм прозаик Рөстәм Мингалимнең тууына 85 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе узды.

Кичәдә Татар мәдәният үзәгенең төрле коллективлары артистлары, җырчылар Ә.Әхмәтҗан, Н.Симаева, Х.Хөсәенова, Г.Әюпова, баянчы Р.Локманов катнашты.

Кичәдә шулай ук чакырылган кунаклар: Айсылу Мингалим-Чижевская, аның балалары Дэниэл һәм Ульяна, җырчы Гөлчәчәк Галләмова-Хәсәнова, композитор Тәлгать Хәсәнов, аның улы Таңнур бар иде. Шагыйрь һәм галим Равил Рахмани Рөстәм Мингалим турындагы истәлекләре белән уртаклашты.

Берничә көн әүвәл Татар мәдәнияте үзәгендә студентлар арасында татар квесты узды. Ул Плеханов исемендәге Россия икътисад университетындагы һәм Мәскәү дәүләт юридик университетындагы татарлар якташлыклары тарафыннан төрле югары уку йортларыннан студентлары өчен оештырылды.

Мәскәү шәһәренең «Дар» мәдәни үзәгендә «Чыганакларга кайту» проекты кысаларында «Дастан» күргәзмәсе ачылды. Күргәзмә Бөтендөнья татар конгрессының Милли шурасы тарафыннан игълан ителгән Милли дастаннар елына һәм татар халкының мәдәниятенә багышлана.

Экспозицияне Мәскәү шәһәре мөселманнарының Диния нәзарәте Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә оештырды. Күргәзмә кысаларында татар халык дастаннары, китаплар, рәссамнар һәм фотографлар эше тәкъдим ителгән. Чарада татар мөнәҗәтләре, бәетләр һәм халык музыка уен коралларында композицияләр башкарылды. Анда Татарстанның халык артисты Гөлзада Сафиуллина һәм «Риваять» этнотөркеме җитәкчесе Руслан Габитов чыгыш ясады.

Күргәзмәдә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәшит Гаимовның «Идегәй» эпосына офорт техникасында ясалган иллюстрацияләре, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Булат Гыйльвановның эшләре, Татарстан Фотографлар берлеге әгъзалары Рамил Гали, Р.Якупов, С.Исхаков, Р.Муллаяновның фотосурәтләре тәкъдим ителә. Шулай ук «Идегәй» татар халык дастаны: Нәкый Исәнбәтнең җыелма текстны өйрәнүгә һәм булдыруга керткән өлеше» күргәзмәсе дә оештырылган.

● Дөньяда нибары 251 генә дәүләт булса да, барлыгы 7 меңләп тел һәм 40 мең чамасы диалект исәпләнә. Шул телләрнең 800 дән артыгы – Папуа-Яңа Гвинеядә яшәүчеләрнеке.

● Үзара аралашу өчен 1887 елда уйлап чыгарылган халыкара ясалма телнең авторы – Варшава окулисты Лазарь Заменгоф, аның псевдонимы Эсперанто («Өметләнүче») булган, тел дә шулай атала.

● Һәркемгә мәгълүм @ билгесен руслар «собачка» дип атый, ивритта исә ул «штрудель», чех һәм словак телләрендә «маринадланган сельдь» дип атала, күпчелек исә әлеге символны «маймыл» дип йөртә.

● Бугенвиль утравындагы (Тын океанда) ротокас телендә 12 генә хәреф бар, бу – дөньяда иң кыска әлифба. Иң озын алфавит исә – Камбоджадагы кхмер телендә, ул 74 хәрефтән тора.

ҖЫРЛАП ЯШИК,

ЯКИ

Онытылмаслык юбилей

Татар дөньясында гаҗәеп хәлләр булып ята. Татарстанның халык артисты Илфат Камалиев бәлагә тарыган, көне-төне компьютер уеннары уйнап, дөньясын оныткан, имеш. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе җитәкчесе Рәмис Латыйпов драматургка әйләнгән, диләр. Шулаен-шулай да, әмма шулай ук түгел. Бәлагә таручы – Илфат түгел, аның сәхнә герое Әхәт. Рәмис Латыйпов та редакциядәге эшен ташламаган, бары Г.Кариев театры өчен И.Камалиевнең юбилеена багышлап пьеса язган. Һәм театрның баш режиссеры Ренат Әюпов әсәрне сәхнәләштергәч, кариевлеләр шау-гөр килеп юбилей билгеләп үтте.

Артистның юбилеена багышлап спектакль кую Кариев театрында матур гадәткә әйләнде. Тамашачыга – яңа сәхнә әсәре, юбилярга – кинәнеп уйнарлык тамаша. Шунысы әһәмиятле, бу бенефис-спектакльләр бер-ике уйналгач та сәхнәдән төшеп югалмый, чөнки һәркайсында көн кадагына суга торган мөһим проблемалар күтәрелә. Артист, драматург, режиссер Фәнәвил Галиевне искә алып сәхнәләштергән «Корт» спектаклендә мил-

ләтебезне корт урынына ашаган көнчелек темасы күтәрелде. А.Әхмәтгалиеваның пьесасы буенча Халидә Сөнгатуллинаның гомер бәйрәме уңаеннан иҗат ителгән «Яратып туялмадым» тамашасында беренче профессиональ театр артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның тормышы бәян ителә. Шул ук авторның пьесасы буенча Рәмзия Закирҗанованың юбилеена сәхнәләштерелгән «Матур City»спектаклендә тышкы кыяфәтләренә артык әһәмият биреп, чынлыкта буш, мәгънәсез кешеләр аша чын кыйммәтләрнең тоныкланып калуы фаш ителә һ.б. «Җырлап яшик» спектаклендә виртуаль дөньяның чын тормышны алыштыра баруы кызык та, шул ук вакытта аяныч та итеп сурәтләнә. Һәр спектакль җиңел итеп, уен-көлке катыштырып, мавыктыргыч рәвештә куелганга, тамашачының мәхәббәтен яулады; күңелсез нотык укуга кайтып калса, театр сөючеләрнең гайрәтен чигерәчәген аңлап, режиссер махсус комедия жанрын сайлаган булса кирәк.

Татарстанның халык артисты Илфат Камалиев утыз ел сәхнә тотып, бик күпләрнең яраткан актерына әйләнде. Аның амплуасын бертөрле генә билгеләве кыен. Тискәре рольләрне уйнаса, дөньяда аннан да явызрак һәм яманрак беркем юк сыман тоела. Бер үк вакытта җиңел комедияләрдә дә ул тамашачыны эче катканчы көлдерә ала. Илфат сәхнәне яраткан кебек, сәхнә дә Илфатны ярата. «Печән базары», «Зәйтүнәкәй» спектакльләрендәге – Тукай, «Башмагым»да – Галимҗан, «Мәкер һәм мәхәббәт»тә Фердинанд һәм дистәләгән башка баш рольләр моңа дәлил булып тора. Илфатның зур бәхете – иҗат юлында режиссер Ренат Әюповны очратуы.

Илфат сәхнәдә генә түгел, гаиләдә дә бәхетен тапты. Тормышта фикердәшеңне табудан да зуррак тагын нинди шатлык бар?! Хатыны Энҗе Камалиева шулай ук Кариев театрының йөзен билгеләүче актриса. Кызлары Илүсә Камалиева Казан театр училищесында режиссер Фәрит Бикчәнтәев курсында белем ала, эти-әнисе белән бер сәхнәдә «Ак чәчәкләр кебек...» спектаклендә уйнады.

«Җырлап яшик» спектакле Илфатның үзе турында. Компьютер уеннарына чумып, башын югалтмаса да, сәхнә герое Әхәт кебек, ул да яшьлегендә музыкаль ансамбль оештырган була, вакыт үтү белән коллектив таркала. Әмма гитара Илфатның да, сәхнәдәге Әхәтнең дә гомерлек юлдашы булып кала. Улын өйләндерү өчен зур акча кирәк булгач, гитараны сатарга кызганып, Әхәт компьютер уенына чума. Танклар уенында отып, генерал була, имеш. Хатыны, улы үгетләвен колагына да элми. Хәтта «муниципалитет Зәмзәмия», телевидение тапшырулары аркылы һәркемгә яхшы таныш дәвалаучы Малышева һәм экстрасенс та Әхәтне акылга китерә алмый. Бер көнне азуы шул дәрәҗәгә җитә ки, үзе кебек уенга башы-аягы белән кереп баткан бичараларны өенә чакырып, команда туплый. Андагылар да акчага мохтаҗ Әхәтнең үзе кебек авыр хәлдә. Кәүсәрия, мәсәлән, Балык Бистәсе Күгәрчен авылыннан килгән, акча туплап Кытайга бармакчы, шунда үзенә кияү эзләмәкче. Азнакайдан Миләүшә кредит түли. Чүпрәледән Ришат, мәктәпне япканнан соң, эшсез калган. Шушы икенчел геройлар аша гына да пьеса авторы Р.Латыйпов бүген адәм баласына тыныч яшәргә ирек бирмәгән никадәр проблема күтәргән. Әхәтне купшы туй үткәрергә хыялланган улы гына түгел, көн саен, җебегән, булдыксыз, мескен дип колак итен ашаучы хатыны да уенга этәрә. Автор хатын-кызның соң дәрәҗәгә җитеп азуын, ир-атка баш булырга омтылуын калку итеп сурәтләгән. Спектакльдә Әхәтне коткарып, кире гаиләгә кайтаралар, без исә балаларыбызны социаль челтәрләрдән аера алырбызмы, әллә көне-төне телефон экранына төбәлеп, күзсез һәм надан калырмы алар? Бу спектакль – һәр тамашачыга уйланыр өчен бер дигән мөмкинлек.

И.Камалиевкә юбилеен яшьтәшләре – Кариев театрының күренекле артистлары белән билгеләп үтү бәхете эләкте. Энҗе Камалиева, Лилия һәм Илнар Низамиевләр, Алия һәм Фәнис Кәлимуллиннар, Гөлнара Абитова, Гөлнара Фазылҗанова, Әминә Галиеваның кайсын гына алсаң да, үзе бенефис-спектакль уйнарлык артистлар. Низамиевләрнең улы Искәндәр дә бу тамашада беренче зур ролен башкарды. Илназ Хәбибуллин, Муса Камалов, Ләйсән Большова яшьләрне гәүдәләндерде. Сценограф Анна Новикова сәхнә конструкциясен музыка уен кораллары кылларына охшаш буй-буй сузылган биш рәт чыбыклар белән ураткан. Сәхнәне күрүгә, музыкантларның биш юллык нота дәфтәрләре күз алдына килә. Театрның якын дусты – композитор Камил Котдусов музыка иҗат иткән. И.Камалиевнең гитара уйнап башкарган җырлары спектакльгә ямь өсти.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

«НУР» ТЕАТРЫ КАЗАНГА ҖЫЕНА

Фирзәт Фәрит улы Габидуллин Туймазы районының Фрунзе авылында туган. Уфа дәүләт сәнгать институтын тәмамлаган. Башта театрда актер була, 2005-2020 елларда Туймазы театрын җитәкли. 2020 елда Уфа «Нур» татар дәүләт театрының директоры итеп билгеләнде.

– Театрда өченче сезон эшлисез, үзгәртәм дип килгән идегезме? Нәрсәгә әлегә тешегез үтмәде?

– «Театр безгә тиклем яшәгән, безнең белән дә яши, театр бездән соң да яшәячәк» дигән хикмәтле сүз бар бит. Театрның үз йөзе, үз юлы бар, мин биргә революция ясарга дип килмәдем. Театрның мәсләге аның репертуары аша ачыла. Бәлки... нәрсәгәдер әлегә тешем үтми, көчем җитми, дип тә әйтеп буладыр, әмма әкренләп, барысы да көйләнер.

«Нур» театры – башкала театры. Зур татар театры! Элек читтән караганда, ул үз казанында кайнаган кебек иде. Театр Иглинга, Кушнаренкога, Чакмагышка чыга, 2-3 елга бер тапкыр Казанга бара иде – шуның белән вәссәлам. Минем театрны фестивальләргә алып чыгасым, зур гастрольләргә йөртәсем килде. Ләкин пандемия сәбәпле әллә кайларга барып булмаса да, алдагы көннәргә килешүләр бара.

Сезон башында Пермь өлкәсендә фестивальгә катнаштык – бу артистлар өчен дәрескә тиң. Грозныйга бардык – анда бару аерым бер илгә сәяхәт кебек. Ике фестивальдә дә театр белгечләре спектакльне тикшерде. Шулай итеп, кечкенә булса да, сынауларны уздык.

Икенчедән, мине театрның репертуары борчый иде. Чөнки бер чорда «Нур» театры гел комедия уйнарга гына кайтып калган иде. Әле 15 ел буе Туймазыда эшләгән чагында ук режиссерларга: «Театр кеше көлдерү өчен туман», – дип әйтә килдем. Театр икән, комедиясе, драмасы, трагедиясе дә булсын. Шуңа репертуарны үзгәртә башладык. 2023 елның 20 октябрендә – Мостай Кәримнең туган көнендә – аның «Ай тотылган төндә» трагедиясен сәхнәгә чыгарырга җыенабыз. Бу әсәр дөнья кимәлендә язылган. Трагедия уйнаган артист үзен профессиональ дәрәҗәдә ача...

– Яшь чагында үзегез дә уйнаган әсәр...

– Әйе, Акъегетне уйнадым. Шекспирның Гамлетын да уйнадым. Кайсыдыр фестивальдә «Иң яхшы ир-ат роле» призын да алдым. Гамлетны «актерлык осталыгының югары ноктасы», диләр. Тагын да уйнар идем, менә монда күчереп, директор итеп куйдылар. Ә без милли театр икән, милли спектакльләр булдырырга кирәк. Татар-башкорт драматургиясендә милли әсәрләр бик күп: Кәрим Тинчуринныкы, Мирхәйдәр Фәйзинеке һ.б... Казанга гастрольләргә барганда, «Галиябану»ны да алып килергә ниятлибез.

– Гастрольләр һәм репертуар – төп максатыгыз, димәк...

– Теләгем шул: «Нур» театры кассасы янында автобус тукталышына кадәр чират тезелсә иде. Халык килсен иде театрга!

Санасаң, байтак эш эшләнде. Театрның 30 еллыгын үткәрдек. Татарстан белән Башкортстаннан кунакларны күп булды. Башкортстан хөкүмәте 55 урынлы автобус бүләк итте. Җәй буе кыекны капладык – софинанслар белән илкүләм проект кысаларында эшләнде. Алдагы максатыбыз – театрның фасадын матурлау. Тирә-якта территорияне дә матурлыйсы иде.

– Иң авыры репертуарны баетумы, хуҗалык эшләреме?

– Бөтенесе дә катлаулы. Мин һөнәрем буенча төзүче түгел, ләкин ремонт вакытында төзүче дә булып китәсең, кыек башында да йөрисең. Наполеон бит: «Мин, театр труппасына караганда, гаскәр белән идарә итәм», – дигән. Башка труппалар кебек, безнең «Нур» театры труппасы җиңел труппа түгел, шулай булырга тиеш тә. Чөнки артистның мин-минлеге дә бар. Генерал буласы килмәгән солдат – начар солдат, диләр бит. Артистка дәрәҗәле исем дә, яшәү шартлары да, хезмәт хакы да кирәк...

– Сез Туймазыда «труппадагы бөтен артистның фатиры бар» дигән идегез. Ә Уфада артистның торак проблемасын хәл итү мөмкинме?

– Эзләнәбез. Уфа шәһәренең яңа хакиме белән сөйләшүләр бара. Республика программалар күп. Театрлар өчен фатир проблемасы комплексы хәл ителә. Аккан су юлын табар, диләр бит, күп йөз суын түгәргә туры килә.

Туймазыда эшләгәндә, сезон ачылган саен яңа фатир бирәләр, ә өч ел эшләгәч, артист ул фатирны хосусыйлаштыра иде. Хәзер ул да бетте. Бу – бөтен Россиягә килгән бәла инде...

– Фирзәт, сез Азат Җиһаншинны театрга баш режиссер итеп чакыргансыз. Башкорт кешесен татар театрына чакырганда, ризасызлыклар булыр, дигән шикләр булмадымы?

– Булды. Әмма сәнгатьнең милләте юк. Башкорт ни, чуаш, мари, мордва ни – ул чын кеше булсын. Азат Җиһаншин – күп театрларда эшләгән сәнгать кешесе. Актер да, режиссер, директор булып та эшләде. Татар драматургиясенә мөкиббән. Татар классикасын, Туфан Миңнуллин әсәрләрен ярата.

Азат – Баймак егете, анысы – чи башкорт районы. Хәзер чи татарга әверелде. Татар тарихын өйрәнә, хәзер Сәхибҗамал Волжская-Гыйззәтуллина турында спектакль чыгара. Татар театры буларак, үз шәхесләребезне чыгармасак, аны кем чыгарсын?! Сәхибҗамал турында спектакль чыгарып, апрель аенда Казанга алып килсәк тә – дәрәҗә булыр иде.

– Биредәге татар җәмәгатьчелегенең претензияләре булдымы?

– Булды, тик бу – претензия дә түгел, аңлап бетермәү иде: «Җиһаншин башкорт башы белән нишләп татар театрына керә?!» – дип, минем янга да килделәр. Мин матур итеп: «Сез аның кебек эшләгез әле!» – дидем.

Азат куйган спектакльләре белән үзенең чын режиссер икәнлеген раслады. Спектакльләрнең сыйфатлы булуы кыйммәт. Аның спектакльләренә халык килә. Татары, башкорты, урысы – барысы да. Башта андый реакция булыр дип көткән дә идем...

– Театрда дәүләт планын үтәү авырмы?

– Пандемия вакытында авыррак булды. Хәзер ике залны да тутырып эшлибез, дәүләт планнары үтәлеп килә. Халык яраткач, план үтәве авыр түгел, кубәйтмәсеннәр генә инде.

– Билет бәяләренең күләме?

– Билет бәясен үзебез куябыз. Бүген иң кыйммәтле билетларыбыз – 1000-1200 сум. Башка театрлар белән чагыштырганда, бу арзанрак. Рус театрында билетлар, спектакленә карап, 3000 сумга кадәр. Без элек-электән кысмыррак. Татар – сәүдәгәр кеше, һәр тиенен санап тоткан.

«Пушкин картасы» – гаҗәеп яхшы әйбер! Мәктәп программасында булган Островскийны уйныйбыз. Бер сулышта бара. Уфада фестивальгә килгән Сибай, Салават театры артистлары килеп карады. «Бигрәк телегез матур, челтерәп аккан чишмә кебек», – дип сокландылар.

– Татар күбрәк концерт ярата кебек. Бире дә дә шул хәлме? Алдан эстрада артисты килеп киткән булса, спектакльгә билет начаррак сатыла, дип зарланалар.

– Районы-районы белән шулай. Кайсыдыр районда – спектакльне, икенче районда концерт яратмыйлар. Туймазы, Бүздәк, Октябрьский якларында концертка да, спектакльгә дә бихуш. Анда Ришат Төхфәтуллин яки Филүс Каһировтан соң «Нур» театры килеп төшсә, зал туп-тулы була.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.
intertat.tatar

Рәмис АЙМӘТ

Зур уенның уенчыгыдыр без, Чорсыз чорның көйсез җырыдыр...

ЗУР УЕН

Когда все умрут, только тогда
кончится Большая игра...
Редьярд Киплинг

Дөнья буйлап тагын Уен бара,
Уенның да әле Зурысы.
Җир тирәли ничә әйләнепләр
Сыналганы, вәхши, кырысы.

Уен бара...
Дөнья базарында
Кемдер алдый, кемдер алдана.
Кемнәр калыр икән күтәрәмгә,
Кемнәр итәр икән тантана?!

Үз мөнбәрен даулаганда доллар,
Ялый бара рубль үз урынын.
Кысык күзле юань өмет өзми,
Чөйгән була һаман борынын.

Чигәләрне кыса дәүләт чиге,
Җанны таптый дәҗҗал өере.
Ничәнче көн инде бугазларда
Зур уенның канлы төере.

Ялган антлар, буш вәгъдәләр инде
Тараталмас шөбһә, шикләрне.
Бер гөнаһсыз гомеркәйләр белән
Сипләнәдер дәүләт чикләре.

Җаннар кыеп очкан ядрә кебек,
Чәрдәкләнгән хисләр, бәгырьләр.
Нинди уеннардан убылганын
Белә микән үксез каберләр?

Уен бара, уен... Европага
Зеңләп ябылганда тәрәзә,
Ачыладыр катлам-катлам серләр, –
Кирәк түгел фараз, күрәзә...

Адашканда Уен кырларында,
Саташканда иман, кыйблалар,
Айрым-бойрым казлар көтүедәй
Кыйгак-кыйгак килә кыйтгалар.

«...Яратмаган илдә яшәмә!» – дип,
Кемдер әнә суза җыруын.
«Китмибез!»не* көйлим эчтән генә,
Монда, димен, нәсел, ыруым.

Ирегенә тыю салып, кем соң
Үз баласын анда чит күргән?
Җандай газиз Ватан-Анасын да
Яратмаган хәлгә җиткергән?

Уйлар учагымның ялкыннары
Йөрәгемне көн-төн ялмый ла...
Әти, Әни һәм Ватанны җирдә
Беркайчан да сайлап алмыйлар.

Рәнҗетелгән җанда нәфрәт хисе
Кара барут** кебек төелгән.
Ул шартларга тора...
Иләр көтим
Туган телем кискән бу илдән?!

Зур уенның уенчыгыдыр без,
Чорсыз чорның көйсез җырыдыр.
Качак җаным ак әләмен айкап,
Көн-төн даулый «яшел коридор».

Уеннарның ниндиләрен генә
Күрмәгәндер инде кешелек.
Уен арты уен... Гөнаһлардан
Төшәр сыман күкләр ишелеп.

Уен арты уен... Һич туктамый
Тарих тәгәрмәче әйләнә.
Кыен арты кыен... Барысы да
Корылганга мәкер, хәйләгә.

Зур уенның булмый кечкенәсе,
Зур уенның булмый уены.
Тик кечкенә кеше башкайлары
Татый аның иң-иң кыенын.

Уен бара, уен дөнья буйлап,
Уенның да әле Зурысы.
Җир тирәли ничә әйләнепләр
Сыналганы, вәхши, кырысы...

---

* Г.Тукайның “Китмибез!” шигыренә ишарә.
** Барут – дары.

ДӘҺШӘТЛЕ КӨЗ

...Ә Казанда бүген тоташ яңгыр,
Иләнә күк шикле иләктән.
Үзенекен итә көз, барыбер,
Һични тормый безнең теләктән.

Үзенекен итә дәһшәтле көз –
Уйланылган мең дә бер кәррә.
Тынмас яңгырыдай, һәр нәрсәне
Җиз иләктән быел үткәрә.

Очкан казлары да быел, никтер,
Күкне түгел, җанны кочалар.
Телиләрме, юкмы, алар, барыбер,
Донбасс якларына очалар.

Оча казлар...
Канат очларыннан
Яңгыр түгел, гүя кан тама.
Казлар түгел, кыл иләгән тотып,
Дәһшәтле көз итә тантана...

Сәер яңгыр «юа» Казанымның
Төсе качкан һәйкәл-потларын,
Курку хисе сеңгән диварларын,
Ялагайлык сарган йортларын.

Пакь акшарын ялмый чал кирмәннең
(Үз сүзен ул соң бер әйтерме?)
Ак кәфендәй акшар белән генә
Булса иде күмеп хәтерне?!

Төти яңгыр... Үзенекен итә...
Уйланылган мең дә бер кәррә.
Дәһшәтле көз быел үзе ура,
Үзе суга, үзе җилгәрә.

Баш очында гүя шомга салып,
Тартылгандай яңгыр ятьмәсе.
Киткән казларымның туган якка
Кире кайтыр икән күпмесе?..

ЯҢА ВӘХШӘТ

Ялтучы Җир шарын
кешелек белән киендерә,
ә кешелексез затлар
ул киемне кыскарта...
Евгений Ханкин

Тагын матәм, тагын матәм көне,
Туктый белмәс нинди матәм бу?
Бер Ходаем, шушы шомлы сүзгә
Сала күрче, зинһар, син табу.

Табу сал син сугыш дигән сүзгә,
Террор дигән сүзгә сал табу.
Кояшымда, Аемда да аның
Бер кәррә дә калмасын табы.

Тагын матәм... Көн-төн күкләр елый.
Нишләдең син, илем, нишләдең?
Әллә Каф тау арты җеннәренең
Юш килдеме икән төшләре?

Әллә океан арты җилләренең
Кагылдымы бозлы сулышы?
Әллә инде гөнаһ җимешләре
Өлгергәнме икән тулышып?

Син, чынлап та, Ватан-Ана булсаң,
Коткысына бирелеп ятларның,
Утка салмас идең балаларың,
Үги күрмәс идең аларны.

«Үтил» җаннар, кайнар каннар белән
Ашлана җир бүген, ашлана.
Иттарткычта заман батырлары, –
Яңа дәвер шулай башлана.

Нинди ил бу? Нинди дәүләт, Ватан?
...Һәркөн матәм, һәркөн мәрасим...

Үз кыйбласын җуйган дәүләте дә,
Бер иблистән туган, күрәсең.

Тагын террор... Дөрләп яна-яна
Араларда өзелә күперләр.
Өзелгәндә иман күперләре,
Ачыла бара йозаклы серләр.

Бер мизгелдә аһылдашып ава
Күккә ашкан йортлар. Җан яна.
Канат җәеп очкан очкычлар да
Җир йөзенә төшеп каплана.

Кая гына бакма – хәрабәләр.
Шомга салып меңнәр йөрәген
Һәр почмакта, чатта Газраилдәй
Сагалый күк террор өрәге.

Афәт ятьмәсендә балык кебек
Чәбәләнә халык, йа, Раббым...
Бу дөньяда шәфкать, мәрхәмәттән
Вәхшилеккә бары бер адым.

Йолып ал син, Ходам, кешелекне
Яңа ялганнарның явыннан,
Яңа йолаларның давылыннан,
Яңа ялаларның авыннан.

Туктата күр террор тантанасын,
Юк, калдырма аның эзен дә.
Кирәк булса, гүргә иңдерербез,
Без Үлемнең хәтта үзен дә.

ХАЛӘТ

Күптән йолдыз санамыйм мин күктән,
Кабызмыйм мин кысыр хыяллар.
Иңри-иңри убылдымы әллә,
Җан тирәве – өмет-кыялар?

Күккә багыйм дисәм, никтер һаман
Гел түбәнгә иелә башларым.
Күктән йолдыз түгел, санап йөрим
Җиргә атылган йолдыз ташларын.

КАЙТУ

Кайтуы җиңелме? Күңелне
Әнә шул уй телә.
Луиза Янсуар

Бер киткәчтен кабат кайтулары
Ай-һай, җиңел түгел икән ул.

Эзен җуйган хисләр арбасына
Икеләтә җигел икән ул.

Бер киткәчтен...
Кабат кайтып тору
Кирәк булды микән? Кирәктер.
Онытылу утравына китеп,
Кабат кайталганнар сирәктер.

Кайтып барам...
Иске тузаннарны
Өмет яңгырлары югандыр.
Мине көтеп илһам чишмәләре
Элеккедәй мөлдерәп тулгандыр.

Урап узам тере мәетләрне,
Сәламемә лаек кемнәр бар?
Төзме һаман терәк-баганалар?
Үзме һаман матур ялганнар?

Җандаш саналганнар, тугры калып,
Каршы чыгарлармы юлыма?
Булыр әле Әҗәл чалгысын да
Тотып чыгучылар кулына.

Ни булса да, мин кайтырга булдым,
Мин әйтергә булдым сүземне.

Рухны кыйган өрәк-мәхшәрләрдән
Араларга булдым үземне.

Үз-үземә якынайган саен
Кайту шөбһәләре күңелдән
Таралалар, китеп болытлардай...
... Монда күпме хисләр күмелгән...

Ә ул хисләр һаман җылы икән
(Аһ, Үлемсез чакның хисләре!)
Эретә күк бозлы күңелемне
Шул көннәрнең изге төшләре...

АКЛЫК

Карлар ява, гүя салмак кына
Ап-ак дога иңә күкләрдән.
Әллә Ходай бу карларны җиргә
Ак хәбәре итеп җибәргән?

Серле мәкам иңә гүя, теләп
Дәваларга җиһан ярасын.
Ява карлар, ява... тоташтырып
Җирләр белән күкләр арасын.

Кемнәрнеңдер җаны уалыплар
Карлар булып җиргә явамы?
Кабатлана бар да, шулдыр инде
Бу яшәүнең чиксез дәвамы.

Тибрәнгәндәй күкләр бишегендә,
Агылалар алар тын гына.
Шул дулкынга тоташа да күңел,
Сер-могҗиза көтә моң гына.

Күзнең явын ала сихри балкыш.
(Түзеп кара син шул сафлыкка!)
Бер Ходаем Үзе сала сыман
Илаһи бер һәйкәл Аклыкка.

Шундый сафлык! Гүя бу дөньяга
Тәүге тапкыр аваз салганбыз.
Тәүге тапкыр аваз салганбыз да,
Хаталардан хали калганбыз...

Әллә Тәңрем бу карларны җиргә
Ак хәбәре итеп җибәргән?
Карлар ява, гүя салмак кына
Ап-ак дога иңә күкләрдән...

АЗНАКАЙДАГЫ

Мондый атамалы авыллар Татарстанда берничә. Белешмә әдәбиятта Азнакай төбәгендәге Балтачның ничек барлыкка килүе тасвирланмый, бары XVIII гасырда нигезләнгән авыл булуы гына күрсәтелә.



● **Авылга 1740 елда нигез салучыларның берсе Балтач [Уразмәтов] теркәлгән документ фрагменты.**

Төбәктәге дистәләрчә авыллар кебек, Балтач та Казан өязе ясаклы татарлары тарафыннан нигезләнә. Җөри юлыннан мондагы җирләргә иң беренче булып 1740 елда Якуп Тимәшкин, Балтач Уразмәтов, Т. Бакыев, Имәш Уразкин, Биккол Уразкаевлар (барысы 7 ир-ат) күчеп килә. Беренчесе Әхтиял (хәзерге Менделеевск районының Татар Әхтиялы) авылыннан, калганнары Текәштән (хәзер Менделеевск районында Татар Текәше исеме белән билгеле) була (РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1155 сакл. бер.). 1741 елда шул ук төбәкнең Ижтамак авылыннан Рысмәт Бигәшов, Зәет Сәетов һ.б. (барысы 7 ир-ат) килеп утыра. Тагын бер чыганакта Кече Чүмән авылыннан Ишмәмәт Азнаголов һәм Якуп Уразов гаиләләре күчеп килүе турында әйтелә.

Яңа барлыкка килгән авыл баштарак Кыпчак (документта «новопоселенная Кипчак»), аннары Балтач Уразмәтов исеме белән Балтач дип атала. «Кыпчак», «нугай» атамалары төбәк тарихында еш очрый, хәзер дә халык хәтерендә сакланган. Алар кайчандыр монда безнең кыпчак бабаларыбыз яшәвен искәртә.

Ясаклы татарлар килеп утырганда бу җирләр Юрмый волосте карамагында булган. Шуңа күрә аның биләмәчеләре белән 1742 елда договор төзелгән. Берьюлы 40 сум оброк түләп, күченүчеләр җиргә хокукларын беркетә (БР МА, И-1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер.).

1748 елда Балтачта барлыгы 37 ир-ат исәпләнә. Балтач Уразмәтов (чыганакта «Уразмеев»; 48 яшь) уллары Бакый (25), Бикмәт (20), Мәсгут (10) һәм Сәет (5) белән яши. Алар белән бергә теркәлгән Якуп Тимкин (62) һәм Якуп Уразов (30) гаиләләре 1748 елдан соң Туйкәгә күчеп утыра.

1762 елгы ревизия документында авыл беренче тапкыр хәзерге исеме белән теркәлә (чыганакта «Болтасево Кипчак тож» дип язылган.). Анда ясаклы (100 ир-ат) һәм йомышлы (5) татарлар яши. Авыл халкының төп өлешен Балтач Уразмәтов (1696-1755; уллары Бакый, Биккенә, Мәсгут, Сәет) белән бергә килгән Җөри юлы ясаклы татарлары тәшкил итә. 1758 елда авылга Казан өязе Арча юлына кергән Шәмәрдәннән Өмир Исаев гаиләсе (6 ир-ат; икенче хатыны Бәзәкә авылының башкорт сословиесендәге татар кызы), шул ук территориядәге Кәвәлдән Пулатай Ахманаев гаиләсе (4 ир-ат) килеп утыра. 1755 елда Арча юлының Олы Шыңар авылыннан йомышлы татар Бакый Рысмәтов гаиләсе дә (5 ир-ат; уллары Нәзир, Зөбәер, Әлкәш, Зәбир) монда күченә. Әлеге кешедән соң зур төркем ясаклы татарлар (27 ир-ат, шул исәптән Сәфәр Мәмәдәлин (74 яшь), Миңлебай Бикмәтов (59), Госман Балтаев (40), Юлдаш Сөешев (36) һ.б.) күрсәтелә, алар да Олы Шыңарданмы, бу хакта әйтелми. Ревизия мәгълүматын раслап Ишмәмәт Аднаголов үзенең нәсел тамгасын салган. Нәкъ шундый нәсел тамгасы бу юллар авторына Бәләбәй өязе Катай авылы биләмәчеләре (вотчинниклары) тарихын өйрәнгәндә очраган иде.

Балтачлыларның ерак авылларда яшәүче башкорт сословиесендәге татарлар белән элемтәсе күзәтелә. Мәсәлән, бер кешенең хатыны Тансык Ишәева Имән (Сарман районындагы Иске Имән авылы) «башкорты» кызы була. Болар кызларын Кәлшәле Туймазы районындагы авыл) «башкорты» Даут Корбанаевка кияүгә бирә. Шул ук Кәлшәледән ясаклы татар Зәет Шитимов Балтач авылы кызы белән гаилә кора.

1762 елда Балтачта йомышлы («служилый») татарлар бары бер гаиләдән торса, 1782 елга алар күчеп килүчеләр исәбенә шактый арта. Болар турында тулы мәгълүмат беренче тапкыр 1795 елгы ревизия документында бирелә.

1795 елда Балтачта («Балтачево, что на речке Стерлибаш Купчак тож») 53 ир-ат һәм 55 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 63 һәм 60 була) йомышлы татар яши. Бертуганнар Мәҗит, Бәхет (?) һәм Нәзир 1794 елда Уфа казна палатасы указы нигезендә Каргалы бистәсенә сәүдәгәрләр булып күченә. Мактамабаш һәм Миндубай авылларына да күчүчеләр була. Ревизия исемлеге ахырында бертуганнар Зөбәер (45 яшь), Әлкәш (41 яшь) һәм Зәбир (38 яшь) Моратовлар теркәлгән. Алар 4 нче ревизия вакытында ясаклы татарлар булса, 1787 елда казна палатасының указы нигезендә ясаклыдан йомышлы татар сословиесенә күчерелә (БР МА, И-138 фонд, 2 тасв., 22 сакл. бер.).

Балтач авылының («Балтачево Кипчат тож») икенче исемлегендә 1795 елда 46 ир-ат һәм 31 хатын-кыз (1782 елда шул тәртиптә 76 һәм 49) ясаклы татар теркәлгән. Халык саны нык кимүнең сәбәбе – 1795 елда Уразай («Уразаево Тигирмень Илга вершина речки Стерля тож») һәм Татар Кандызы авылларына күченеп китүчеләр булу. Беренче авылга күченүчеләр сөрүлекләр һәм печәнлекләр аз булуны сәбәп итеп күрсәтә. Бу чыганакта да Зөбәер, Әлкәш һәм Зәбир Моратовларның йомышлы татар сословиесенә күчүе турында әйтелә.

Югарыда әйтеп үткән Уразай (Тегермән Елга) авылында 37 ир-ат һәм 35 хатын-кыз ясаклы татар исәпләнә. Монда бары тик Балтачтан һәм Стәрлетамак округының Аллагуват авылыннан күченүчеләр генә яши. Соңгы авылдан Аднагол Бикколов (59 яшь), Уразман Аитов (55 яшь), Сәгыйть Балтачев (55 яшь), Мәхмүт (39 яшь) һәм Гобәйдулла (33 яшь) Мәксүтовлар күчеп килә (БР МА, И-138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер.).

Аллагуват (Башкортстанның Стәрлетамак районында) Ногай юлының Юрматы волостена керә. Бу факт ике татар волостеның (Юрмый һәм Юрматы) тыгыз элемтәләре булуын дәлилли.

1816 елда Балтач Кәкре Елга волостена карый. Сословиеләре буенча халык лашман бурычын башкаручы («исправляющие лашманную повинность») йомышлы һәм ясаклы татарларга бүленә. Беренчеләре – 67 ир-ат һәм 81 хатын-кыз (24 хуҗалык; Мөхәммәтшәрип һәм Рәхимкол Мөхәммәдьяровлар, Әс[ф]әндияр Нө[р]каев, [Г]омәр, Тимербулат, Бикбулат Котлымәтовлар, Мәксүт Мансуров, Бикбулат Биктимеров, Зөбәер һәм Зәбир Моратбакиевлар һәм башкалар) (БР МА, И-138фонд, 2 тасв., 197 сакл. бер.). Икенчеләре – 33 ир-ат һәм 27 хатын-кыз (14 хуҗалык; Мәнәй һәм Мәннан Сәгыйтовлар, Зөбәер Зәетов, Корбанай Морадымов, Габдерәшит һәм Габҗәлил Габдерәззаковлар, Бикташ Колмәмәтов, Туктар һәм Мәҗит Тимәшовлар, Габделнасыр Ишмөхәммәтов, Ильяс Гамбәров, Хәбибулла Тимеркәев, Хәбибулла Мәүлекәев, Надырша Гаделшин, Ишмөхәммәт Ишмәнов) (Шунда ук, 535-540 б.).

Бер чыганакта якындагы Уразай (Тегермән Елга) авылы исеме белән теркәлгән ясаклы татарлар төркеме (39 ир-ат һәм 44 хатын-кыз; Галикәй һәм Кормангали Биккениннәр, Бикчәнтәй Бикколов һ.б.) Балтачка карый дип күрсәтелә. Анда шулай ук тагын бер солдат улы да аерым телгә алына. Ревизия документында бу хакта әйтелми, әмма башка чыганаклар Балтач халкын һәрвакыт Уразай (Тегермән Елга) дип аталган урында яшәүчеләрне дә кертеп исәпли.

Шулай итеп, 1816 елда Балтач халкы 140 ир-ат һәм 152 хатын-кыздан тора. Бу чорда авылда мәчет, Стәрле елгасында (4) һәм Тегермән Елга исемле инештә (1) тегермәннәр була. Аларның хуҗалары – Әлкәй Биккенин, Ильяс Гамбәров, Бикбулат Биктимеров, Мәксүт Мансуров һәм Габҗәлил Бикчәнтәевләр.

1858 елгы ревизия вакытында Балтач кешеләре сословиеләренә карап элеккечә аерымаерым теркәлә. Бер документта дәүләт крестьяннары (135 ир-ат һәм 152 хатын-кыз; 26 хуҗалык) һәм кантонистлар (5 и 4; 4 хуҗалык) искә алына, икенчесендә – шулай ук дәүләт крестьяннары (47 ир-ат һәм 49 хатын-кыз; 12 хуҗалык, шул исәптән 67 яшьлек Минәй Сәгыйтов) һәм отставкадагы солдатлар (3 ир-ат һәм 6 хатын-кыз; 3 хуҗалык). Әлеге дәүләт крестьяннары дип язылганнар (барысы 182 ир-ат һәм 201 хатын-кыз) элеккеге йомышлы һәм ясаклы татарлардан тора.

Балтачның өченче төркем дәүләт крестьяннары (64 ир-ат һәм 86 хатын-кыз; 13 хуҗалык, шул исәптән Байбүре Галикәев) Уразай (Тегермән Елга) дип аталган урында яшәүчеләрдән тора.

Болардан башка, 1859 елгы ревизия документында типтәр сословиесендәге ясаклы мулла Габделхәким Мостафин (57 яшь; уллары Габделгалим һәм Габделбәдыйг) күрсәтелә. Аның гаиләсе 4 ир-ат һәм 7 хатын-кыздан тора. Алар документның титул битендә «башкорт», әчендә «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептярей») дип язылган (БР МА, И-138фонд,2 тасв., 757 сакл. бер.).

Статистик әдәбиятка күз салсак, 1859 елда Балтачта 260 ир-ат һәм 306 хатын-кыз (84 хуҗалык) яши. Алар сословиеләре буенча дәүләт крестьяннары һәм «башкорт»лар дип күрсәтелгән (Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. – С.-Петербург, 1864. г. –

С. 35.). Ревизия документыннан күрдек, «башкорт» дип язылганы указлы мулла гаиләсенә генә туры килә. «Типтәр»ләр (шул исәптән әлеге мулла гаиләсе) 1855 елдан «Башкорт» гаскәрендә саналгач, рәсми чыганакларда сословиеләре буенча «башкорт» дип языла башлый.

Югарыда сүз барган документлардан күренгәнчә, Балтач авылында беркайчан да биләмәчеләр (вотчинниклар) яшәмәгән. Шуңа күрә кайбер авторларның аны Юрмый волосте биләмәчелере авылы дип язулары аңлашылмый. Алар ул авылга нигез салмаган һәм анда яшәмәгән. Татар энциклопедиясе дөрес мәгълүмат бирергә тиеш, әмма анда да Балтачта биләмәчеләр яшәгән, дип язу тарихны бозуга тиң.

БАЛТАЧ

1889 елда Балтачта 165 хуҗалыкта 825 кеше күрсәтелә. Гасыр ахырынарак авыл тагын да зурая: 1897 елда 202 хуҗалык, 531 ир-ат һәм 576 хатын-кыз була. Мәчет, мәктәп һәм 4 су тегермәне эшли.

XIX гасырның соңгы дистәсе игенчелекне әледән-әле авыр сынаулар алдына куя. 1891-1892 елларда корылык аркасында игеннәр уңмый, халык, мал-туар ачлыктан интегә. Аннан соңгы дүрт елда исә икмәк яхшы уңа. 1894-1895 елларда уңыш, 1893 елгыга караганда, югарырак була. Әмма 1898 елны тагын корылык булып, ачлык килә.

Әлеге афәт Балтачтан дистәдән артык гаиләне читкә бәхет эзләп чыгып китәргә мәҗбүр итә. Берәүләрен – кыска срокка, икенчеләрен исә бөтенләйгә. Мөхәммәтгали Сәфәргалиев, мәсәлән, Чиләбедә эшләп кайта. Шакирҗан Вәлиев һәм Әфләтүн Айчуаков 1899 елның кыш-яз айларында Курск губернасына ук барып чыга.

Әмма иң зур тәэсир калдырганы – дистәдән артык кешенең Төркиягә күченеп китүе. Болар – Габдулла Кәримов (хатыны һәм 3 баласы белән), Әһлиулла Габделхәбиров (гаиләсе юк), Гарифулла Габделхәбиров (хатыны, 4 баласы), Хәйрулла Рәхмәтуллин (хатыны юлда вафат була), Хәлиулла Рәхмәтуллин (гаиләсе юк, үзе өлкән яшьтә), Якуп Юнысов (гаиләсе юк), Йосыф Юнысовлар (гаиләсе юк) (ТР ДА, 993фонд, 1 тасв., 31 сакл. бер.).

Балтачта бик күптәннән мәчет эшләп килүе хакында әйтелгән иде. 1882 елдан бирле указлы мулла булып Әхмәтвәли Габделбәдигъ улы Баязитов (44 яшь) тора. Ул хатыны (19 яшь), 3 улы (зурысы 16 яшьтә) һәм 2 кызы белән яши. Мулланың хуҗалыгында 3 эш аты, 4 сыер, 30 сарык һәм төрле вак маллар була. Барлык чәчүлекләре 13,48 дисәтинә тәшкил итә. Шуларның бик азы гына (3,10 дисәтинә) үз иманасында, калганнары авылдашларыннан (5,50) һәм читтән (4,88) арендага алган басуларда. Өстәвенә, Әхмәтвәли хәзрәт зур умарталык (19 баш) хуҗасы да була. Хуҗалыктагы эшләрне башкару өчен үз көче генә җитми, шунлыктан ул даими хезмәтче тота.

Авылның мөәзине (1889 елдан) – Мөхәммәтзакир Гобәйдуллин (40 яшь). Гаиләсе хатыны (25), 2 улы һәм кызыннан тора. Мулладан аермалы буларак, аның хуҗалыгы зур түгел. Анда 2 эш аты, 3 сыер, төрле вак маллар һәм умарталык (3 оя) була. Барлык чәчүлекләре 10 дисәтинәдән аз гына арта.

Мәктәпкә турыдан-туры кагылышлы мәгълүматлар юк. Ләкин авылда ике кешенең укытучылык белән шөгыльләнүе билгеле. Беренчесе – Шәйхулла Нигъмәтуллин (37яшь). Документтан күренгәнчә, бу шөгыль аның елга 5 ай вакытын алган. Хезмәте өчен балаларның ата-аналары хуҗалыкта җитештергән продуктлар белән түләгәннәр. Укытучының хуҗалыгы ярлы: сыер һәм бозау, 3 сарык һәм нибары 1,55 дисәтинә чәчүлек. Җәйләрен ул еш кына көнлекчелеккә йөрергә мәҗбүр була.

Кыз балаларны шулай ук 5 ай – көз (1 ай), кыш (3) һәм яз (1) Әсхәпҗамал Габделгафурова (50 яшь) укыта. Аңа 24 яшьлек кызы ярдәм иткәли. Алар икесе генә яши, бер кәҗәне исәпләмәгәндә башка мал-туары да, чәчүлекләре дә булмый. Бары укытучылык һәм җәй айларында көнлекчелек исәбенә яшиләр.

Авыл тормышын сәүдәгәрләрсез күз алдына китерү кыен. Монда берьюлы 3 хуҗалык лавка тота. Алар арасында Габдулла Мөхәммәтҗанов (37 яшь) аерылып тора. Ул әнисе (85 яшь), хатыны (35 яшь), 2 улы һәм 2 кызы белән көн итә. Хуҗалыгы зур: өчәр эш аты һәм сыер, 2 үгез, төрле вак маллар асрый, күп (20,45 дисәтинә) иген игә. Болардан тыш, 22 баштан торган умарталыгы да була. Хуҗалыкта күп эшләрне хезмәтчесе башкара.

Калган 2 лавка хуҗалары – Хәлиулла Бикмөхәммәтов (35 яшь) һәм Дилмөхәммәт Зөлмөхәммәтов (38 яшь). Мал-туардан берәр эш аты тоталар; чәчүлекләре зур түгел (6-7 дисәтинә).

Лавкалардан чәй-шикәр һәм көндәлек тормыш өчен кирәкле башка товарлар бер дә өзелмәгән. Кирәк-яракны Бөгелмәгә барып Шакир байдан һәм аның кебек эре сәүдәгәрләрдән әледән-әле алып кайтканнар. Кайсы лавкага нинди товар кайткан, бу хәбәр шунда ук өйдән-өйгә тарала торган булган. Күбрәк бертөрлелек хас авыл тормышы өчен үзенә күрә вакыйгага тиң яңалык булган ул.

Балтачта, волостьның кайбер башка авылларына караганда, тегермәннәр күбрәк була. Алар турында тулырак мәгълүмат биреп үтик.

1900 елгы документлардан күренгәнчә, авылда 3 су тегермәне була. Шуларның берсе – Балтач авыл җәмгыяте тегермәне, ул Стәрле елгасында урнашкан. Аны Бөгелмә мещаны Демьян Игнатьев (57 яшь) арендага алган. Тегермәнче монда 4 улы белән яши, хуҗалыгы зур түгел.

Икенче тегермән – Григорий Севастьяновныкы (56 яшь). Ул Балтачка Бөгелмә өязенең Павловка авылыннан күчкән. Монда хатыны (56 яшь) һәм улы белән яши, тегермәндә үзе эшли. Аның 2 эш аты, сыеры, төрле вак маллары һәм 3 дисәтинә чәчүлекләре (авыл кешеләреннән арендага алган басуларда) була.

Исәп буенча өченче тегермән – Михаил Ключиков (43 яшь) милке. Ул тумышы буенча Бөгелмә өязенең Сумароково авылыннан. Гаиләсе хатыны (43) һәм 4 кызыннан тора. Аның мал-туары һәм чәчүлекләре югарыда телгә алынган Г. Севастьяновныкы белән чагыштырганда азрак. Тегермәндә үзе эшли.

1900 елны авыл старостасы булып Муллагали Мөхәммәтгалиев (48 яшь) тора. Бу вазыйфаны башкарган өчен ул хак алмаган. Староста хатыны (45 яшь), улы (22 яшь), 3 кызы һәм килене белән көн күрә. 2 эш аты, сыер, 3 сарык асрый һәм 12,08 дисәтинә мәйданда иген игә.

Җәләлетдин Фазлытдинов (54 яшь) десятник вазыйфасын үти. Аның гаиләсе ярлы яши. 23 яшьлек өлкән улы Ивановка авылында эшкә ялланган, калган 2 улы Балтачта көтү көтә. Мал-туары булмый, чәчүлекләре нибары 2,73 дисәтинә тәшкил итә.

Балтачта, кайбер тирә-як авыллар белән чагыштырганда, умартачылык белән шөгыльләнүчеләр күп була. Кайбер умартачылар турында алдарак әйттек. Алардан башка, тагын Мөхәммәдьяр Мөхәммәтҗанов (44 яшь) – 31, Әхмәтгали Мөхәммәтгалиев (30 яшь) – 20, Мөхәммәтгали Миңлекәев (29 яшь) – 15, Хәлфетдин Мөхәммәтәминов (40 яшь) 7 баш умарта тота. 4 хуҗалыкта (Әсхәп-жамал Габделгафурова, Мөхәммәтситдыйк Мөхәммәтҗанов, Нурмөхәммәт Мәнәев, Әхмәтша Мөхәммәтгалиев) исә бу күрсәткеч зур түгел (2 дән 5 кә кадәр).

Әмма хуҗалыкларның төп шөгыле элеккечә игенчелек һәм терлекчелек була. Иманаларының күләме зур булмаганлыктан, казнадан һәм якын-тирә алпавытлардан арендага җир алучылар күбәя. Шул ук вакытта кайбер ярлы хуҗалыклар үз иманаларын арендага биреп ел әйләнәсенә көнлекчелеккә йөри яисә батрак булып эшли. Мәсәлән, Сәлимгәрәй Айчуаков (35 яшь) Чемодуровка авылы янындагы алпавыт Головинская имениесендә 1899 елның 1 мартыннан 15 октябрьгә чаклы бил бөгә. Әхмәтвәли Габделвәлиевнең (61 яшь) улы Сумароково авылы тирәсендәге Шпилев хуторына ялланган. Берничә кеше Елачич имениесенә көнлекчелеккә йөргән.

Балтачта күп мал-туар асраучы хуҗалыклар шактый. Бу яктан бигрәк тә Әхмәтһади Габделбәдигов (33 яшь) аерылып тора. Ул 5 эш аты, 4 сыер, 2 үгез, 36 сарык һәм 7 кәҗә асрый. Хезмәтче яллаган.

Дүртәр эш аты һәм берничә (икедән алып дүрткә кадәр) баш сыеры булган хуҗалыкларга тукталып үтик. Бу исемлеккә Мөхәммәтгали Вәлиев (52 яшь), Мөхәммәтситдыйк Мөхәммәтҗанов (56 яшь), Гафиятулла Вәлиуллин (35 яшь), Гыйльфан Вилданов (30 яшь), Юныс Шәрәфетдинов (48 яшь), Фәхретдин Мөхәммәтәминов (46 яшь), Хәлфетдин Мөхәммәтәминов, Мөхәммәдьяр Мөхәммәтҗанов һәм Сәетбаттал Шәрәфетдинов (43 яшь) керә. Соңгы өчесенең хезмәтчеләре була.

Югарыда телгә алынган хуҗалыклар авылда иң эреләрдән санала. Балтачта күп иген игүчеләр – алар. Хәлфетдин Мөхәммәтәминовның, мәсәлән, чәчүлекләре 17 дисәтинәдән арта. Болар инде таза хәлле хуҗалыклар катлавын тәшкил итә.

Өчәр эш аты һәм берәр-дүртәр сыер тотучы хуҗалыклар тагын да күбрәк. Алар исәбенә (язмабызда телгә алынганнардан тыш) Әхмәтгали Мөхәммәтгалиев, Шәйхетдин Латыйфуллин (40 яшь), Нурмөхәммәт Мәнәев, Әхмәтгали Мәнәев, Габделгалим Сәгыйтов (60 яшь), Мөхәммәди Мөхәммәтҗанов (55 яшь), Гыймадетдин Ихсанвәлиев (44 яшь), Габдулла Мөхәммәтҗанов, Мөхәммәтгали Миңлекәев, Хәйрулла Вәлиуллиннар (40 яшь) керә. Аларның берничәсе хезмәтче тота; күпчелегенең чәчүлекләре 10 дисәтинәдән арта. Боларны чын мәгънәсендә урта хәлләр дип атарга була.

Авылның югарыда күрсәтелгән ике катлавы базар белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Аларның төп өлеше үзләреннән арткан мал-туарны һәм икмәкне сатарга алып чыга, байый. Капиталистик Россиядә авыл хуҗалыгы продуктларына кытлык бөтенләй булмауны менә шул катлауларның эшчәнлеге, тырышлыгы белән аңлатырга кирәктер.

(Ахыры киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

Атнаның сәяси мизгелләре

Си сәфәргә җыена

Кытайда узган атнада 14 нче чакырылыш Халык вәкилләре Бөтенкытай җыенының беренче сессиясе тәгәлләнде. Ул 8 көн (5-13 март көннәрендә) дәвам иткән. КХР рәисе Си Цзиньпин, ил тарихында тәүге мәртәбә, әлеге вазыйфага өченче срокка сайланган. Сәяси күзәтүчеләр исә Пекинның Вашингтонга карата конфронтация курсы алуын да искәртә. Ә моңа кадәр Кытай Украинада низагны деэскалацияләү башлангычы белән дә чыккан иде. Россия белән дә ул тотрыклы мөнәсәбәтләр урнаштыру яклы, ә аңа каршы санкцияләр Украинада кризисны киметмәячәк, дип саный. Киләсе атнадан Си Цзиньпин Кытайның яңа курсын гамәлгә кую буенча берничә илгә сәфәргә дә җыена. Аның барышында ул Россия Президенты В.Путин белән дә очрашыр кебек. Вашингтон исә аңа Украина президенты белән дә туры элемтәгә керергә киңәш иткән.

Узган атнада вәзгыять Грузиядә дә катлауланып алды. Парламентта «иноагентлар» турында Россиядәге кебек закон проекты әзерләүләренә каршы протест акцияләре 6 мартта башланып киткән. Аны беренче укылышта кабул иткәч, протест акцияләре тагы да көчәйгән. Полиция 7-8 март көннәрендә 133 кешене тоткарлаган. Протест акцияләре көчәеп, халык сәяси таләпләр дә куя башлагач, хакимият закон проектын караудан алырга мәҗбүр булган, тоткарланган кешеләр дә азат ителгән. Мәскәүдә инде Тбилисидәге протестларны Киевтәге мәйдан белән чагыштырганнар. Закон проектының кире алынуы Тбилисидәге хәлләрне бераз тынычландырган кебек.

Инде атнаның игътибарны җәлеп иткән кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. Россия кораллы көчләре, Украина диверсантларының Брянск өлкәсендә кылган һөҗүменә үч итеп, 9 март көнне бу илнең хәрби инфраструктурасын тупланышлы ракета утына тоткан. БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш Россиядән ашламаларны каршылыкларсыз экспортлауга ярдәм вәгъдә иткән. Россиянең 90 сугышчысы Украина әсирлегеннән алыштырып алынган. Мәскәү русофобияне Украина кризисын хәл итүгә комачаулый торган фактор буларак тану темасына БМО КШ утырышын җыюга гариза биргән.

Фоат УРАЗАЙ.

БУМЕРАНГ

Алмаз ӘХМӘТГАЛИЕВ

(Ахыры. Башы 9 нчы санда.)

Гөлшат әзерләгән ризыклардан табын сыгылып тора иде. Бәлеш, май күмәче, хуш ис аңкытып торган аш, дисеңме. Монда ни сорасаң, шул бар!

Балалар өстәл янына утырды. Алар табын артына утырса да, Хәсән бабай бисмилләсен әйтеп кашыгын алмыйча, ризыкка үрелмәделәр.

Хәсән бабай өстәл янына утыргач сүз башлады:

– Көтү чиратын матур гына үткәрдек, көн яңгырсыз булды. Балалар, барыгызга да зур рәхмәт!

Хәсән бабайның рәхмәт сүзеннән соң, беркем дә дәшмәде. Өстәл янында бары тик тәлинкә белән кашыклар гына серләште.

Көтүчеләр чәй эчкәндә, кемдер ишек шакыды.

Хәсән бабай:

– Улым, бу сиңадыр. Килгән кешене озак көттерергә ярамый, бар ишекне ач.

Ишеккә дөбердәткән кеше Илшатның дусты Илдус икән. Ул аны комлыкта уйнарга чакырып килгән.

Илшат:

– Илдус, бүген комлыкта уйнамыйбыз, миңа Хәсән бабай бумеранг бүләк итте.

Илдус:

– Миңа да очыртып карарга бирерсеңме?

Илшат:

— Әлбәттә бирәм.

Кечкенә Илшат өеннән тиз генә бумеранг алып чыкты да дусты Илдус белән уенлыкка йөгерде. Әле анда зурлар килмәгән иде. Шуңа күрә алар рәхәтләнеп уйнады. Бумерангны да — башта берсе, аннары икенчесе очыртты.

Ике дус тату гына уйнаганда, куаклар арасыннан Кылдый Фәнис пәйда булды.

Кылдый Фәнис:

– Әй, сез, малай-шалайлар, монда нишләп йөрисез? Иркенләп балык тотарга да ирек бирмисез.

Кечкенә Илшат, аңа җавап итеп:

– Без бумеранг очыртабыз, Хәсән бабай миңа бумеранг бүләк итте.

Кылдый Фәнис малайлар белән сүз куертып тормады. Ул аларга:

– Шаулашмый гына уйнагыз да абыйларыгыз килгәч, өегезгә таерсыз! – диде.

Балык яхшы кергәнгәме, Илшатның бумерангы булгангамы, ул аны бу юлы рәнҗетмәде...

Кояш Зиректауның очына кунгач, уенлыкка берәм-берәм зурлар килә башлады. Озак та үтмәде, үзенең бумерангын күтәреп, монда балык тотып йөргән Кылдый Фәнис тә килеп җитте. Ул күзләре белән тиз генә дус-ишләрен барлап чыкты да Илшат белән Илдус янына атлады.

Кылдый Фәнис:

– Әй, малай-шалайлар, мин сезгә нәрсә әйткән идем, сез мине аңламадыгызмы?

Илдус үзенең дусты Илшат артына посты. Ә Илшат Кылдый Фәнискә тагын җавап кайтарды:

– Хәсән бабай миңа бумеранг ясап бирде. Хәзер Илһам абый килергә тиеш. Без аннары кайтабыз!

Кылдый Фәнис:

– Бумерангым бар, дисең, инде. Аның исеме ничек?

Илшат:

– Аның исеме юк, Фәнис абый! Нинди исем кушарга кирәк соң аңа?

Кылдый Фәнис, шаркылдап көлде дә Илшатка карап:

– Татарча берәр кош исеме инде.

Кечкенә Илшат:

– Ак шоңкар, ак шоңкар була аның исеме.

Кылдый Фәнис:

– Бүгеннән бумерангның гына түгел, синең тәхәллүсең дә ак шоңкар булачак!

Илшат Кылдый Фәнис белән кызып-кызып сөйләшкәндә, Илдус ютәлләп куйды.

Илшат:

– Фәнис абый, ә Илдусны, күршем Илдусны ни эшләтәбез? Ул бит минем иң якын дус.

Кылдый Фәнис:

– Аны да үзебез белән ияртербез, бумерангы булганчы синекендә өйрәнер.

Кылдый Фәниснең бу гамәленә башкалар бик нык аптырады. Алар үз төркеменә бумерангсыз кешеләрне ияртмиләр иде.

Кылдый Фәнис, Илшат белән Илдуска:

– Малай-шалайлар, безнең төркемдә буласыгыз килсә, сез бер сынау үтәргә тиеш.

Илшат белән Илдус бер-берсенә карашып:

– Фәнис абый, нинди сынау?

Кылдый Фәнис:

– Авыл өстендә тилгәннәр оча башлады. Сезгә өч көн буе бәбкәләрне сакларга кирәк. Шул өч көн эчендә үрдәк, каз бәбкәләрен тилгән алып китмәсә, төркемебезгә ияртәбез. Ә хәзер, малай-шалайлар, өегезгә кайтыгыз.

Каяндыр Илһам абзыйның тавышы ишетелде:

– Илшат, Илдус сез уенлыктамы? Әйдә, кайтыгыз, монда хәзер җеннәр уянып чыгачак.

Кечкенә Илшат андый әйберләргә тиз ышана иде. Ул, үзенең дустын ияртеп, абыйсы янына элдерде. Ә икенче көнне Илшат белән Илдус бәбкә сакладылар.

Кылдый Фәнис биргән сынау ансат кебек тоелса да, җиңел булып чыкмады. Өч көн булды дигәндә: бер үрдәк бәбкәсен тилгән урлап китте. Кечкенә Илшат, шул бәбкәне коткарыр өчен бумеранг атып, Кылдый Фәнисләрнең өй тәрәзәсен ватты.

Бу вакыйгадан соң Илшатның җае җәй булмады. Капка төбенә чыкканда да, иң беренче авыл башына күтәрелеп карады. Өстәл янына утырган саен, Казанга кайтасы килүен әйтте.

Шулай кача-поса йөри торгач, җәйге каникулның соңгы көннәре килеп тә җитте.

Гөлшат:

– Әткәй, безгә китәргә кирәк инде. Син борчылма, без кайткалап йөрербез.

Хәсән бабай:

– Яхшы, кызым. Юл кешесенең – юлда булуы хәерле!

Хәсән бабай ике кулын бер-берсенә кушып дога укыды да кызы Гөлшат белән оныгы Илшатны капка төбенә кадәр озата чыкты. Казан-Малмыж автобусы үтеп киткәч, ул түбәтәен эскәмиягә куеп, балаларына хәерле юл теләп, кулларын болгап калды. Ә үзе: «Балаларым, тагын кайтыгыз, мине онытып бетермәгез», – дип, яшел чирәм өстенә утырды.

Көн артыннан төн узды, төнгә ияреп сентябрь, октябрь, ноябрь. Гөлшат авылга кайткалап йөрсә дә, кечкенә Илшат аңа иярмәде. Хәсән бабай оныгының уңышлары турында бары тик кызы Гөлшаттан гына белеп торды. Шулай итеп айлар, еллар узды.

Бер көнне Илшат әнисе белән табында унсигез яшен билгеләп үткәндә, кемдер ишек шакыды.

Әнисе:

– Улым, бу сиңадыр, ач ишекне.

Илшат бабасы әйткән сүзләрне исенә төшереп:

– Әнкәй, аңладым. Килгән кешене озак көттерергә ярамый, хәзер ачам.

Илшат кунак көтмәсә дә, аларга ниндидер таныш йөзле бер бабай килгән иде. Ул аны түр ягына чакырып өстәл янына утырткач, бабай сүз башлады:

– Улым, мин бик картайдым. Хәтерем дә начарланды. Сиңа хәзер ничә яшь?

Илшат бу картны үзенең Хәсән бабасы икәнен аңлап алды һәм аны кочып:

–Унсигез тулды, Хәсән бабай, унсигез!

Хәсән бабай:

– Ууу, Илшат улым, зур булгансың. Соңгы тапкыр күрешкәндә сиңа алты тулган идеме?

Илшатның ике бите дә алма кебек кып-кызыл булды, ул бабасына ниләр булганын, ни өчен авылга кайтмаганын сөйләп бирде.

Хәсән бабай, оныгы Илшат сөйләгәнне тыңлап бетергәч, куеныннан тастымалга төргән, урак айга охшаган әйбер алды. Кесәләрен бераз капшаганнан соң хат чыгарды.

Бу хат – авыл малайларын куркытып торган Кылдый Фәнистән иде.

Илшат ипләп кенә хатны ачты да әкрен генә укый башлады:

«Нихәл, энекәш! Бу мин – Фәнис абыең булам. Илшат, сиңа шуны әйтәсем килә: мин биргән сынауны үтәдең. Безнең каз бәбкәләрен саклаганда, бумеранг белән тәрәзәбезне ваткач, әти-әнидән миңа шәп эләкте. Өч көн буе өйгә кайтмый йөрдем. Ярый, анысы хәзер мөһим түгел. Озын сүзнең кыскасы шул: теге вакытта Бурсык Илдусын яклап чыккан өчен, мин сине хөрмәт итәм. Мин шуның белән хатны тәмамлыйм. Язасы килгән сүзләрем бетте. Безнең авылга кайткалап йөр, бер кешегә дә тидертмәм. Сине көтүдән каршы алган сеңелем көтә. Бумерангыңны Хәсән бабайга илтеп бирдем».

Кылдый Фәнис усал, хәйләкәр егет булса да, аның әйткән сүзе корычтай нык иде. Моны хатта күрше авыл малайлары да белә.

Хәсән бабай, оныгы Илшатның янында тынычлык урнашканын сизгәч, бумерангны аңа янә сузып:

– Улым, бу гади әйбер түгел, моны явыз ният белән очырсаң – явызлык, яхшы ният белән очырсаң, яхшылык кайтыр, – дип пышылдады.

Балалар әдәбияты кем өчен?

Балалар әдәбияты, аның баланы туган телгә өйрәтү, кызыксындыру чарасы буларак урыны, иң элек, балалар язучысыннан тора. Ул чын талант булу белән бергә, көчле педагог һәм психолог та булырга тиеш. Чөнки балалар әдәбияты үз эчендә генә яши торган мөстәкыйль фән түгел.

1) Ул – гомумәдәбиятның бер тармагы. Димәк, сүз сәнгатенең барлык таләпләренә дә җавап бирә;

2) Әмма, аның үзенә генә хас билгеләре дә бар. Ул тәрбия кануннарына, педагогия һәм психология таләпләренә буйсына: тәрбия мәсьәләләре, яшь үзенчәлеге, баланың ихтыяҗы, зәвыгы, танып-белү мөмкинлеге, тәҗрибәсе күздә тотыла.

Балалар әдәбияты буенча ясалган чыгыш-докладлардан соң миңа «безне мактамыйсың», дигән үпкә сүзләре дә әйтелә. Шулайдыр, әмма карашым биредә үзгәрәк:

1) Бүгенге авторларның күпчелеге, нигездә, үткәндәге тема-образларны кабатлау – начаррак сыйфатта кабатлау белән шөгыльләнә. 2) Яки, еш кына, балалар психологиясен белмәгәнлектән, әсәрләр «бала образы кергән, әмма, өлкәннәр өчен язылган» булып чыга...

Нәтиҗәдә, тәрбияче-мөгаллимнәр алдына зур бурыч килеп баса: дөрес, уңышлы әсәрләрне сайлап алу, шуның аша бала күңеленә тел-әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту.

Әлбәттә, балалар әдәбиятының нигезендә балалар фольклоры ята. Әби-бабаларның акылы, гафу итегез, безнең бүгенге күп казанышлардан өстен тора: нигезе Ислам диненә, Коръән һәм Хәзрәте Мөхәммәднең хәдисләренә бәйле принципларга таянган Татар тәрбия системасында, фәнни һәм дини тикшеренүләр күрсәткәнчә, «бала, анасының карынында чакта ук хис итәр, өйрәнер, тыштан килгән тавышларны исендә калдырыр һәм бу мәгълүматны соңыннан хәтерләр». Моны аңлаган әби-бабаларыбыз ана карынында ук балага зур игътибар биргән, соңрак, әлеге карашларны фольклор жанрларында туплаган да.

Фикерне дәлилләп бер генә мисал китерик. Мавыктыргычлар жанрыннан, «Бармаклар» уены (баланың бармаклары белән уйнала):

Карга килгән – казан аскан,
Чыпчык килгән – бәрәңге әрчегән.
Торна килгән – аш бушаткан,
Тилгән килгән – бүлгән,
Моңар биргән, моңар биргән,
Моңар биргән, моңар биргән,
Моңар бирмичә калдырган.

Моңа кадәр әлеге уен галимнәр тарафыннан бер яссылыкта гына – әхлакый тәрбия яссылыгында, «Эшләмәгән – ашамый» идеясе белән бәйләп каралды. Әмма, мәгънә биредә күпкә тирәнрәк, югыйсә.

1. Әлбәттә, тәрбия мәсьәләсе;

2. Мавыктыргычта сүзләр уены бар. Бер үк сүзләр кабатлана – баланы телгә өйрәтүдә бу алым әһәмиятле, шул рәвешле сүзләр бала хәтеренә сеңдерелә. (Бу ысул бүгенге көндә реклама өчен уңышлы файдаланыла). Текстта м, р, п, т авазларының еш кабатлануы үзенә бер төрле яңгыраш тудыра. Бу хәл баланың игътибарын теленең яңгырашына җәлеп итә, димәк, туган теленең нигезен үзләштерү күнекмәсе туа;

3. Яңа төшенчәләр үзләштерү мөмкинлеге арта. Карга, Чыпчык, Торна – кош исемнәре. Бала сөйләүче артыннан кабатлап, яңа сүзләр үзләштерә, сөйләм теле, белем ягыннан байый, туган тел нормалары формалаша.

4. Сәламәтлек мәсьәләсе. Бүгенге көндә кул терапиясе (терапия рук) «чорның яңа үсеш технологиясе» дип бәяләнә. Аның нигезендә исә, моторика күнекмәләрен үстерү өчен күнегүләр җыелмасы ята. Бу терапия ярдәмендә кулларның нейромускуляр һәм скелет системасы яхшыра. Бала кулларын ышаныч белән контрольдә тота башлый, хәрәкәтләре төгәлләшә – балаларның уйлау сәләте, хәтер, игътибар, сизү, уйлау һәм, әлбәттә, сөйләм камилләшә. Галимнәр әлеге терапия ярдәмендә, «теләсә нинди яшьтәге балаларның психо-сөйләм проблемаларын тиз һәм нәтиҗәле төзәтергә мөмкин», дип раслый. Димәк, бүген «яңа үсеш технологиясе» дип аталган ысулны меңәр еллар элек үк безнең әби-бабаларыбыз белгән һәм аның аша аерым авыруларны кисәтергә омтылган булып чыга түгелме?! Чөнки уен барышында баланың һәр бармагына, сөйләүче тарафыннан массаж эшләнә, шунда ук баланың кәефе дә күтәрелә, тәрбия дә ала, яңа сүзләр өйрәнә һәм милли телне, аның яңгырашын да истә калдыра.

Моннан күп еллар элек Лондонда яшәүче танышым белән уртак мәкалә язарга уйладык. Аның нигезендә инглиз һәм татар балалар фольклоры үрнәкләре чагыштырма планда бәяләнергә тиеш иде. Әмма, тәрбия мәсьәләсендә уртаклыкны табу гаҗәп авыр булып чыкты. Дөрес, белем бирү юнәлешендә аларда да кызыклы әсәрләр байтак. Мәсәлән, атна исемнәрен өйрәтү өчен кулланылган мавыктыргыч:

Бәбием ничә көн уйнарга тиеш?
Шимбә, Якшәмбе, Дүшәмбе,
Сишәмбе, Чәршәмбе, Пәнҗешәмбе,
Җомга, Шимбә, Якшәмбе –
Сикер, уйна,
Бәбием уйнарга тели,
Бәбием һәр көн уйнарга тели.

Күренә ки, фольклор әсәрләре милли тәрбия системасында гаять әһәмиятле урын тота.

Балалар әдәбияты формалашканчы ук, татар балалар укуында кызыклы әсәрләр байтак булган: фольклор әсәрләре, Хуҗа Насретдин мәзәкләре һәм классик әдәбият үрнәкләре. Н.Исәнбәт бер мәкаләсендә: «Мәдрәсәләрдә... уку программасы кызлар өчен «Йосыф китабы»н көйләп укуга хәтле барып җиткән», – дип яза. Әсәрдә күтәрелгән идея-темалар үзенчәлекле, әлбәттә. Әмма бу очракта безнең өчен иң кызыклысы – Йосыф образы.

Чөнки ул үрнәк образ. Балалар әдәбиятында үрнәк ярдәмендә тәрбия кылу үзәк алымнарның берсе. Үз вакытында Ленин, Сталин образлары тасвирланган калын-калын китапларның ел саен нәшер ителүнең сәбәбе дә шунда иде. Халыкның балаларда күрергә омтылган теләк-хыяллары, тел, белем, затлылык – Йосыф образында ачыла:

Беренчедән – буе зифа, сылу үзе,
Икенчедән – күрекле һәм якты йөзе,
Өченчедән – теле бик саф, туры сүзле,
72 телне тәмам белә имди! ...

Инде, татар балалар әдәбиятын нигезләүче Каюм Насыйри иҗатына күчик. Аның «Әбүгалисина кыйссасы» – иң танылган әсәре. Төрек язучысы Зыятдин Сәеднең «Кәнҗинән хикмәт» исемле әлеге әсәрен К.Насыйри 1872 елда тәрҗемә итеп, әдәби эшкәртеп «Әбүгалисина кыйссасы» исеме белән бастыра. (Әбүгалисина – 908-1037 елларда Ибне Сина, Авиценна исемнәре белән мәгълүм, Урта Азиядә яшәгән фәлсәфәче, әдип, астроном, музыкант, энциклопедист галим).

К.Насыйриның әлеге әсәрне тәрҗемә итәргә алынуы очраклы хәл булмый, әлбәттә. Мәгърифәтчелек идеяләре күтәрелгән «Әбүгалисина кыйссасы»н халык аңларлык итеп, рус мәмләкәтендәге мөселманнар теленә тәрҗемә кыйлсам икән дип, күп заманнан бирле күңелемдә бар иде», – дип ул, әсәрнең әһәмиятен үзе үк ассызыклый.

Әсәр дәвамында бирелгән вакыйгалар аша идея ачыла. Кеше акылының көчен, аң-белемнең бөтен нәрсәдән өстен булуын күрсәтү – бу әсәр үзәгенә алынган төп фикер. Идея үсештә карала. Белем – кешеләргә ярдәм һәм яхшылык юлында гына файдаланылырга тиеш, югыйсә нәтиҗә аяныч булырга мөмкин дигән фикер кыйссадагы һәр вакыйга – хәрәкәт аша укучыга җиткерелә.

Үз чоры һәм бүгенге көн өчен дә кызыклы, кирәкле әсәр. Әмма ... бу көннәрдә «Әбүгалисина кыйссасы» буенча куелган спектакльнең өзеген карарга туры килде. Инсценировка авторы – Айгөл Әхмәтгалиева, режиссеры Гульназ Минкина, композиторы Алмаз Әсхәдуллин. Әсәрне карый башлагач, гаҗәпләнүемнең чиге булмады: Әбүгалисина хатын-кыз җенесеннән. Тәүбә, әстәгъфирулла!

Тормыш үзгәрә, буыннар алмашына, башка өлкәләр белән бергә әдәбият һәм сәнгатьтә дә яңалыклар көтелә һәм, кирәк тә! Әмма ул бит тарихны, миллилек, традицияләрне юкка чыгару, классик әсәрләрне тамырыннан үзгәртү юнәлешендә барырга тиеш түгел. Әбүгалисина төрки дөньяга мәгълүм ир-егет! Аны хатын-кыз итеп күрсәтү белән автор нәрсәгә ирешә? Нинди яңалык кертә һәм нигә кирәк бу? Сораулар ачык кала...

Сүз уңаеннан, мине гаҗәпләндергән тагын бер вакыйгага тукталыйк. Бу көннәрдә Кави Нәҗми һәм аның хатыны Сәрвәр Әдһәмованың мәхәббәте турындагы «Кави-Сәрвәр» операсы тирәсендә бәхәсләр бара. (Айдар Әхмәдиев, Миләүшә Хәйруллина). Шушы уңайдан, «Таяну ноктасы» тапшыруында авторлар белән булган сөйләшүне карарга туры килде. Айдар Әхмәдиевнең фикерләреннән, аеруча гаҗәпләндергәне «миллилек җитми» тәнкыйтенә биргән җавабы булды: «Биредә сүз совет чоры, 1937 нче еллар турында бара бит. Анда миллилек артык мәҗбүри түгелдер». Гаҗәп...

1923 елда Мәскәүдә СССР халыкларының үзәк нәшрияты оештырыла һәм биредә 32 телдә матур әдәбият нәшер ителә. Нәкъ менә милли әдәбиятларны саклап калу өчен. Анда М.Җәлил, Һ.Такташ кебек шагыйрьләр белән аралашканнан соң мари әдибе Виктор Мухин түбәндәге сүзләрне язып калдыра: «Татарлар зурдан кубып фикер йөртә, безгә дә алардан калышырга ярамый!»

Ләйлә МИНҺАҖЕВА,
филология фәннәре докторы.

Без Бәгәрәк Тамак мәктәбен нигезләгән Г.Җәмилев барельефы янында.

Без Кунашак районы башлыгы С.Әминев белән.

Урал татарлары:

Чиләбедә үтәчәк чараларның яртысы мәгълүм бөекләребезгә чәчәк салу белән йотыласы булгач, андый көн тәртибен күңелебез кабул итә алмады. Ерак сәфәргә чык та, чәчәк салып йөре – кемгә, нинди фәтва? Күңел күптән Кунашак районына тарта иде, анда 1957 елгы «Кыштым фаҗигасе»н кичергән Мөслим белән Караболак атлы татар авыллары бар, шундагы милләттәшләребез ничек яши, алар һаман газап кичерәме? Һәммәсен үз күзләребез белән күрәсе, сорашасы, белешәсе килә. Мин фәкыйрегез район башлыгы Сибәгатулла Әминевка шылтыратуга ук, ул Чиләбедән безне килеп алырга махсус машина юллады. Маршрутны да үзләре билгеләгән. Ләбиб Лерон һәм Рөстәм Галиуллин белән шул районга киттек.

Чиләбедә шигырь антологиясен тәкъдим итү кичәсеннән соң.

Караболак Чиләбедән 80 чакрым чамасы ераклыкта, Екатеринбург юлының уң ягында икән. Урамына керүгә үк йөрәкләр жу итте. Аны фашистлар бомбага тоткан, яман сугыш кичергән авыл, дип тә булмый, әмма берике хуҗалыкны уздыңмы, ике-өч ташландык йорт. Теге «бер-ике» дигәненең дә капка төпләре бөтенләй күрәлмәгән, димәк, андагыларның да әби-бабасы юк, ә ул йә кызлары аларны җәйгелек дача итеп кенә тота. Авыл туфрагының адәм күзе кызыгырлык һичбер шифасы калмаган, ләкин «кендек туган нигезгә береккән» дигән гыйбарәне тиктомалдан гына әйтмиләр шул...

1940 еллар ахырында ук Кыштым янәшәсендә Озерск каласы һәм үтә яшерен «Маяк» комбинаты төзелә, аны бернинди документ яки карталарда да искә алмыйлар, ул «Чиләбе-40» атлы объект булып кына йөртелә. Химия, асылда исә атом комбинаты булган әлеге предприятие шул елларда ук Теча елгасына үзенең производство калдыкларын агыза башлый. Ә 1957 елның 29 сентябрендә анда коточкыч шартлау була. Комбинат төн буе шәфәкъ яктысыдай кызыл төскә чумып яна, аның утын якыннан күрүчеләрнең күзе сукырая. Комбинатның агулы калдыклары Теча елгасы буенча Озерскидан 40-50 чакрымда яткан Караболак, Мөслим, Бәгәрәк авылларына агып килә. Галимнәр соңыннан ачыклаганча, «Маяк» комбинаты тирә-юньгә 20 миллион кюри агулы матдә тарата, нәтиҗәдә Свердловск, Чиләбе, Курган өлкәләре буйлап сузылган 267 мең кв. км мәйданда (Татарстаннан дүрт мәртәбә зуррак) өч миллионга якын кеше, Чиләбе өлкәсенең Кыштым, Кәсле, Аргаяш, Кунашак тирәсендә генә дә 437 мең адәм баласы агулана. Җирле халыкны бер оешма да коточкыч хәвеф турында кисәтми. Аның Чернобыль фаҗигасенә тиң авария булуы хакында 90 нчы елларда гына искә төшерәләр.

Дөрес, «Маяк»та авария булып узуга ук, Мәскәү каласыннан махсус комиссия килеп төшә. Биредәге коточкыч мәхшәрне күрүгә, комиссия комбинатны ябып куярга тәкъдим ясый. Ләкин аңа хәрбиләр каршы төшә, чөнки бөтен Җир шарын чыбыркы шартлаткандай өркетеп торачак атом бомбасын булдыру күпкә кадерлерәк бит...

Авария шундук дәүләт серенә әверелә. Шулай да, зыян күргән 12 мең кешене 70 көннән соң Озерскидан башка төбәкләргә күчереп утырталар. Терлекләр яндырып юк ителә. Радиация белән тоташ агуланган татар авыллары телгә дә алынмый, үз урыннарында калдырыла. Төгәл ике елдан соң, 1959 елның 29 сентябрендә Чиләбе өлкәсенең башкарма комитеты Бәгәрәк халкын, шулай ук Караболак авылындагы 2700 кешене «Такталым» совхозының Әшир авылына күчерү турында карар чыгарып, шушы максат өчен Мәскәүдән 98 һәм 78 миллион сум акча да сорап карый, әмма үзәктән тишек бер тиен дә төшми. «Чарасын үзегез күрегез», дигән фәрман юллыйлар. Бәла «җиңел» хәл ителә: «Татар Караболагы» атлы авылның «Татар» аергычын алып ташлыйлар. Хәвефле элекке авыл шулай «юкка чыга», ә авыл юк икән, проблема да беткән, нәкъ кансыз Сталинча...

Ә югыйсә, Караболакта 1957 елда гомер итүчеләр саны өч мең чамасына якынайган була. Чүп өстенә чүмәлә, дигән шикелле, 1967 елда коточкыч гарасат кубып, ул «Маяк» комбинатыннан агулы калдыклар аккан Карачай күленең суын күккә күтәреп ала да, әлеге кара болыт янә Караболак өстенә килеп түгелә. Бу кадәр хафа эзсез уза алмый, 25 ел эчендә генә дә

Усман авылында 1908 елда төзелгән кибет бүген дә эшли.

Караболактагы ташландык йортларның берсе.

Юкка чыккан Мөслим авылы урынында калган мәчет хәрабәсе.

● Караболак авылы үзәге.

● Альберт хәзрәт белән Төбәк авылы мәчете каршында.

Чиләбе

Караболакта мең ярым кеше вафат була. Аннан соң да 500 гә якын кеше рактан җәфа чигә. Нәтиҗәдә авылны 8 зират чолгап ала... Ни кызганыч, әлеге коточкыч һәлакәт хакында татар дөньясында Фәүзия Бәйрәмовадан кала беркем дә чаң сукмады, тагын да аянычрагы – сыңар гына җитәкче дә аны ишетмәде...

Тарихына керсәң, Татар Караболагы – документларда 1547 елда ук искә алынган авыл. Әле аңа кадәр дә биредә татар сәүдәгәрләре үз кәрваннары белән туктала һәм чатыр-тирмә корып яши торган була. Казан ханлыгы егылып төшкәннән соң, 1553-1556 елларда бирегә Казан тирәсеннән, көчләп чукындырудан качкан татарлар килеп өстәлә. Революциягә кадәр үк караболаклылар саны меңнәр белән исәпләнә. 1919 елның июль аенда Караболак һәм Мөслим авыллары аша кызылларның 5 нче армиясе, алар составында В.Чуйков отряды узып китә. Шушы төбәктә булып узган бәрелешләр вакытында гына да якынтирә татар авылларыннан 1500 чамасы ир-егет һәлак була. Власть ияләре моны тиз оныта, утызынчы елларда НКВД отрядлары барча муллаларны җыеп ала һәм алар эзсез юкка чыга. Мәчет манараларының һәммәсен дә кисеп төшерәләр, гыйбадәт йортлары склад һәм мастерскойларга әверелә. Хәтта Бәгәрәк Тамак авылына советча мәктәп төзеп биргән Җәләлетдин Камаловны да 1937 елда атып үтерәләр. Бөек Ватан сугышы кырына Кунашак районы 6680 ир-егетне озатып җибәрә...

1956 елда Караболакта рәсми теркәлү узган кешеләр саны ук 2800 дән дә арткан була. 1970 елда алар саны – 1934 кә, ә 2002 елда 578 гә кала. Бүген хәрабәләр белән тулы авылда 250 чамасы кеше яши, ләкин араларында инде очсыз хакка хуҗалыклы булып калырга атлыккан урыслар да, үзбәк-таҗик та бар. Бакчада нибары ике үзбәк баласы тәрбияләнә, 20 мәктәп укучысы 16 чакрымдагы Береговой авылына, урыс мәктәбенә йөри. Атом калдыкларын үзендә күмгән өчен генә дә, безнең илгә Европа дәүләтләре ел саен икешәр миллиард доллар акча түләп тора, тик Караболакта атом радиациясе чиреннән газап чиккәннәргә сыңар тиен дә таммый. Авылда бүген яшәп ятучыларның йортларына газ торбасы суздарлык та маясы юк...

Мөслим авылы урынында хәзер – фәкать хәрабәләр. Ә югыйсә, 1730 еллар тирәсендә үк нигезләнгән тарихи авыл булган! 1745-1748 еллар чамасында биредә атаклы Батырша – Башкортстанның Балтач районында туган Габдулла Галиев муллалык иткән. Авыл 1735 елда башланган Акай фетнәсе һәм 1755 елгы Батырша фетнәсенә, 1774 елда Пугачев гаскәренә яугирләр бирүе белән данлыклы. 1767 еллар тирәсендә бу авылда атаклы географ Паллас та булып киткән. 1957 елгы «Кыштым» фаҗигасе алдыннан анда 3500 гә якын кеше гомер иткән. Тик 2002 елда анда 2100 чамасы, 2010 елда 464 кенә кеше яшәп калган. Авыл җирендәге агу микъдары сәгатенә 12 мең рентгенга җиткән, диләр, ә адәм тазалыгы 40-60 рентгенны гына кичерә ала икән. Ходай рәхмәте белән, ниһаять, аның халкын 2010 елда Яңа Мөслим дигән авылга күчергәннәр. Иске урынында агач мәчет, 1889 елда бертуган Злоказовлар төзеткән биш катлы тегермән хәрабәләре чекрәеп утыра, тагын 5-6 бина калдыгы бар. Бөек Ватан сугышында һәлак булган туганнарына багышлап биредә куелган һәйкәлне дә, дүрт кисәккә бүлеп, Яңа Мөслимгә күчергәннәр. Яңа авылда мәктәп бинасы да, йортлар да бик сыйфатлы, ләкин ул барыбер җанын җуйган сыман. Мөслимлеләр яки караболаклыларга Чернобыль фаҗигасен кичерүчеләргә карата булдырылган льгота, пособие, өстәмә түләүләр дә кулланылмый, бушлай санаторий да эләкми...

● Төбәк авылында менә шундый йортта да яшиләр әле.

Без алга таба кузгалып, Усман авылында, Бәгәрәк Тамакта, район үзәге Кунашакта (татарлар үзләре аны Коншак, кына ди), бүген күршедәге Кәсле районына кергән Төбәк авылында да булдык. Усман авылын 1670 еллар тирәсендә мишәр катламына язылган татарлар нигезләгән, 1735 елда Акай фетнәсе башлангач, мондагы ирләрнең бер өлешен Төбәк авылына казаклар сыйфатында күчереп утыртканнар, 30 ар дисәтинә җир дә өләшкәннәр. Ләкин власть куштаны булып йөрүне болар өнәмәгән, ахры, бүгенге йорт-хуҗалыкларының сыйфатын һич кенә дә затлы, диярлек түгел. Усманда да инеш урталай бүлгән авылның бер ягына газ кертелгән, икенче ягы һаман утын ягып көн күрә, аның каравы, «Себер куәте» дип аталган торбалар Кытайга кишер бәясеннән газ куа. Бәгәрәк Тамакка да газны 18 ел буе җирле үзидарә рәисе булып эшләгән Э.Газизова-Борһанова гына турыдан-туры «Газпром» җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп керттерүгә ирешкән. Гәрчә әлеге Бәгәрәк үз вакытында район үзәге булып та торган әле, Курган өлкәсенә терәлеп яшәгәнгә күрә генә, үзәкне Кунашакка күчергәннәр. Бәгәрәк тә иске, 1708 елда ук нигезләнгән. 1920 елларда халык саны 3200 гә җитсә дә, бүген 400 дән дә артмый. Урта мәктәпләрендә якын-тирәдәге 13 авыл балаларын җыеп укыталар, арада башкорты, урысы, хәтта үзбәге дә бар. Татар теле соңгы елларда гына дәрес буларак атнасына ике тапкыр керә башлаган, шуңадыр, ахрысы, балаларның татарча белүе бик нык аксый. Без үскәндә мәктәпләрдә дәрестән соң төбәкне өйрәнү, тарих, математика, җырбию түгәрәкләре гөрләп эшли иде, ләкин мондагы мөгаллимнәр аларны оештырып, андагы күнегүләрне татар теленә алып бара алмый, чөнки дәресләр тәмамлануга ук балаларны автобус көтеп тора. Монысы да – зур кимчелек, бу өлкәдә дә – упкын...

● Караболак авылындагы моңсу мәчет.

Район үзәгендә бик шәп яңа мәктәп төзеп куйганнар, шәһәрдәгеләр дә көнләшерлек. Ләкин анда да татар дәресләре гөрләп тормый. Районның 73 авылында яшәүче 28 мең кешенең 47 процентын – башкорт, 36 процентын – татар, 14 процентын руслар тәшкил итә. Район үзәгенә яки Бәгәрәк Тамак авылына Тукай бюстын кую өчен дә ашкынмыйлар, алай итсәң, башкорт халкы үпкәли, янәмәсе. Иллә мәгәр төбәк музейларына махсус хәрби хәрәкәттә һәлак булган егерме якташларының рәсемнәрен тезеп куйганнар, барысы да тик мөселман гына. Ярый әле мәчетне бүләсе юк, анысы матур булып, үзәктә балкып тора. Район башлыгы С.Әминев төбәк музеен да яңартып төзү яклы...

Шулай итеп, без бу төбәкнең алты авылына күз йөгертеп чыктык, ни кызганыч, барча тарихына чумарга өлгермәдек. Чиләбенең үзендә татар активистлары белән түгәрәк өстәл һәм шушы өлкәдә яшәп иҗат итүче әдипләрнең шигырь антологиясен тәкъдим итү кичәсе көтә иде, шуңа күрә юлга ашыгырга туры килде. Түгәрәк өстәл артында янә хөкүмәтнең җанисәпкә уен итеп кенә каравы, ә санауга барыбер фәкать үзәк кенә нәтиҗә ясавы кат-кат яңгырады. Соңгы ике җанисәп арасында Чиләбе өлкәсендә яшәүче татарлар саны 60 меңгә киметелеп, 120 мең генә итеп күрсәтелә икән, хөкүмәт «вак» милләтләр белән үз кесәсендәге көнбагыш яисә бакыр акча белән уйнагандай идарә итә, дигән сүз бу. Татар, башкорт, чуаш, мари Кыштым фаҗигасендә кырылды ни дә, җанисәптә тоташ йотылды ни, үзәккә аерма юк. Автономия хокукына ия республика, край һәм өлкәләр үзара берләшеп, хакыйкать дауламаса, мондый ялганның киләчәктә дә чәчәк атуы бар.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

«Талантлы һәм тыйнак иде»

Татар рәссам-графигы Рөстәм Курамшин менә инде унбер ел бакыйлыкта. Ә аның әсәрләренә сокланучылар саны артканнан-арта гына бара.

Булачак рәссам 1960 елның 2 гыйнварында ТАССРның Баулы (хәзерге Ютазы) районы Урыссу эшчеләр бистәсендә дөньяга килә. Мәктәптән соң, 1975-1980 елларда Лениногорск музыка-сынлы сәнгать педагогика училищесында уңышлы укый. Аннары Бөгелмә шәһәренең урта белем мәктәпләрендә сынлы сәнгать һәм сызым дәресләрен алып бара. Бөгелмә сынлы сәнгать мәктәбендә укыта, Бөгелмә, Азнакай предприятиеләрендә рәссам-бизәүче булып та эшли. Татарстан Рәссамнар берлегенең Бөгелмә бүлегендә дә хезмәт куя.

1987-1991 елларда И.Я.Яковлев исемендәге Чабаксар дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетында гыйлем ала. Шунда укыган чорда офортлар ясау белән мавыгып китә.

Рөстәм Раил улы 2008 елда – Татарстан Рәссамнар берлегенә, ә 2010 елны Россия Рәссамнар берлеге сафларына кабул ителә. Ни кызганыч, ул 2011 елның 3 июлендә кинәт кенә вафат була.

2014 елда Казанда Рөстәм Курамшин һәм Булат Мәрдәнов иҗатларына багышланган күргәзмә ачыла. Мәрхүм Булат Мәрдәнов та Бөгелмә рәссамы, акварель сәнгате остасы. Ачылыш тантанасы вакытында рәссамның җәмәгате Ләлә ханым Курамшина болай дип ассызыклый: «Рөстәмне кылкаләмдәшләре бик яратты, алар хәзер дә хәл белешеп тора, күргәзмәләренә чакыралар. Менә бу күргәзмәгә дә күпләр килде. Димәк, ул чын дус була белгән! Рөстәм, мине, әйтерсең лә, үз каләмдәшләренең игътибарлы мөнәсәбәтенә тапшырып китте. Күргәзмә ачылыр алдыннан төш кердем, имеш, поездда барам һәм ике ир-ат басып торганын күрәм – Рөстәм белән Булат. Якты кояш нурлары... Йөзләрендә елмаю. Алар шушы күргәзмә ачылуга шатланалар булыр. Кызганыч, исән чакта Казанда Рөстәмнең шәхси күргәзмәләренең ачылганы булмады...»

Татарстанның халык рәссамы Мөдәрис Миңһаҗев бакыйлыктагы иҗатташын болай дип искә алды: «Рөстәм безнең чордаш, бик мәртәбәле, сабыр егет иде. Шулкадәр тырыш булды. Энергиясе, көч-куәте ташып торучы иҗатчы. Бигрәк тә көчле график буларак дан казанды. Зур күргәзмәләрдә аның эшләре янында һәрчак халык җыела иде. Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорскида күргәзмәләре еш булды. Рөстәмне бик хөрмәт иттем. Хәтеремә ул чын һөнәрмәнд, күңелгә ятышлы шәхес булып кереп калды. Аз сүзле булса да, күңеленә туры килгән чакларда рәхәтләнеп, таралып сөйләшә дә белде, сәнгать турында затлы фикерләре булды, гомумән, ул йөрәктә чын дус булып уелып калды... Аның үлем хәбәре көтмәгәндә яшен суккандай булып килеп иреште...»

Күңелләргә үтеп керешле, сокландыргыч әсәрләр... Алар нәфис тә, катлаулы да. Рөстәм Раил улы хезмәтләрендә табигать күренешләре фотосурәттәге мизгелләрне хәтерләтә төсле, әмма шул ук вакытта алар үтә җанлы, монда табигать сулышы да яхшы тоемлана.

Рәссам Фәрит Газизуллин да Рөстәм Раил улы хакындагы истәлекләрен барлады: «Апам, рәссам Рабига Круглякова аны яхшырак белә иде, чөнки алар күбрәк аралашты. Без Рөстәм белән Бөгелмәдә уза торган күргәзмәләрдә күрешеп, хәләхвәл белешә идек. Исемдә, бер күргәзмәдә Рөстәм зур күләмле картинама игътибар итте, бик ошатты.

Аның улын да күреп беләм, ул табиблык һөнәрен сайлады, нәкъ әтисе кебек игелекле, яхшы күңелле ир-ат! Рөстәм тыйнак та, кешеләргә игътибарлы да, эш сөючән дә иде шул! Бәхәсләрне бер дә өнәмәде. Йөрәк чиреннән шулай тиз китеп барыр дип кем уйлаган... Аның үлеменнән соң, җәмәгате үтенече белән, Рөстәм иҗаты буенча каталог төзеп бирдем. Остаханәсендәге барлык әсәрләрен барлаганда, аларны камиллек дәрәҗәсенә җиткерү өчен күп көч түккәннен аңладым, тәмамланмаган хезмәтләрен дә беренче тапкыр шунда күрдем. Остаханәсендә көйләр яздырылган аудиокассеталар, дисклар бихисап иде... Рәссамнарның күбесе төрле музыка тыңлыйтыңлый иҗат итә, ул да шундый нечкә күңелле, көйләр сөюче зат булган. Рөстәмнең иҗат эшләрен дәүләт учреждениеләренә тәкъдим итүдә дә башлап йөрергә насыйп булды. Әлхәмдулилләһ, Р.Курамшинның иллегә якын иситкеч график әсәреннән өчәр хезмәте Бөгелмә туган якны өйрәнү музеенда, Әлмәт картина галереясында, Казанның 1000 еллыгына багышлап ачылган музейда саклана. Рөстәмнең графикасы Татарстан Рәссамнар берлеге нәшер иткән альбомнарга да кертелде.

Шушы елларда аның иҗатына багышланган «Сагышым якты» дип аталган күргәзмә Бөгелмә каласының Татар мәдәнияте үзәгендә дә ачылды, зур уңыш белән үтте. «Болар яшь иҗатчылар өчен чын үрнәк әсәрләр!» дигән сүзләр мондый чараларда еш ишетелә. Көзге, кышкы, язгы пейзажлар, төрле портретлар... Һәммәсе шулкадәр осталык, композиция төгәллеге үрнәге!

Рөстәм заказлар саны артыннан кумады, гел остаханәсендә, иҗатта булды. Мирасының бер өлеше картиналардан да гыйбарәт... Эшләре кадерләп саклана, Ләлә ханым аларны сатып җибәрергә ашыкмый. Төрле күргәзмәләр оештырганда, кайберләре шунда экспозицияләнә».

Р. Курамшин иҗатының киләчәк буыннар өчен сакланып калуы шатлык хисләре уята, әлбәттә. Бәлкем, күләмле шәхси күргәзмәсе Казанда ачылыр әле. Ни дисәң дә, рәссамлыкка укучы яшьләр өчен мондый күргәзмәләр тансык.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● «Габит хәзрәт»

● «Әтием»

● Автопортрет.

● «Яз»

«Татар җырын тыңлап үссеннәр»

Автор-башкаручы Фирүзә әңгәмәне үзе туып-үскән Актаныш районы белән горурланудан башлады: «Актаныш – татар халкына данлыклы Әлфия Авзалова, Минтимер Шәймиев, Алисә Галләмова, Гамил Афзал кебек шәхесләрне биргән төбәк».

– Фирүзә, әүвәл укытучы булырга укыгансың. Ничек җырлый башладың соң?

– Җавап өчен, балачакка кайтмый булмый бугай. Мәктәптә укыганда инша язарга ярата идем. Татарча да, русча да! Гел бишле куйдылар. Киләчәктә җыр язу уемда да булмады. Мәктәптә укыган вакытта интернет юк иде бит. Китапханәләрдә югалып, аның атмосферасына чумып, төрле китапларга кызыксынучлар куеп, шуларны укмаштырып, иншалар яздым. Әдәбияттан олимпиадалар буенча 1-2 нче урыннарны алдым. Аннары безнең гаиләбез җыр сөючән. Әти дә, әни дә җырлый. Ләкин мәктәптә укыганда, җыр белән түгел, күбрәк бию белән шөгыльләндем. Татар һәм башкорт биюләре белән Казандагы финал турына үтәм, әмма башкалага барырга совхозның акчасы табылмый иде. Бервакыт ритмик биюләр белән район этабын үтеп, Казанга барасы идек, булмады.

«Җырлап та, биеп тә була. Төпле белем ал, кызым», – диде әни миңа, мәктәпне тәмамлагач. Дөресен әйткәндә, әни табиб булуымны теләде. Ул үзе дә табиб. Әмма мин каннан курыктым. Медицина өлкәсе минеке түгел. Шуңа укытучы һөнәрен сайладым. Алабуга педагогика институтында татар, рус телләре һәм әдәбиятлары укытучысы һөнәрен үзләштердем. Бию, театр түгәрәкләренә йөрдем. «Студентлар язы» фестивалендә җыр белән катнаша башладым. Без төрек телен өйрәнүне белеп, төрекчә дә җырларга куштылар. Ул вакытта фонограмма юк, аны табуы да, яздыруы да авыр иде.

Берсендә әни күрше авылдан фонограмма алып кайтты. «Ләйлә һәм Мәҗнүн» җырына иде ул. Тыңлый башласак, тональлеге минем тавышка туры килми. Нишләргә? Кабатлый-кабатлый тавышымны яраклаштырырга тырыштым, үз тавышымны үзем ясадым. Вокал укытучыларына да йөреп карадым.

– Музыкаль белемсез көй язып буламы?

– Көй ул үзеннән-үзе туа. Студент елларында шигырь түгәрәгенә йөрдем. «Шулмы сөю?» дигән җырның тексты шул елларда язылды. Гаилә корып, икенче балам тугач, көйләр көйләп йөри башладым. Беркөнне «Шулмы сөю?» текстына бер көй килеп чыкты. Шулай итеп, беренче җырым туды. Тора-бара бер дисклык җыр яздырдым, иҗат дөньям шулай башланды. Хәзер инде профессиональ сәхнәдә ун елдан артык кайнайым.

Хисле чагымда, авыр мизгелләрдә миңа йә сүзләр, йә көй килә. Әле күптән түгел генә әни белән сөйләшеп утырабыз. «Тегене эшләдем, моны эшләдем», – дип әни телефоннан сөйли. Хәзер әни ялгыз. Актаныш районының Татар Ямалысы авылында яши. Әтинең арабыздан китүенә 8-9 ай. Минә ялгыз хатынның тормышы... Күршедә дә ялгыз апа бар. Күз алдыма ялгыз хатыннар, аларның көнкүренешләре килә башлады. Ялгыз, парсыз ничек алар гомер итә? Тора-бара «Ялгыз аналар» дигән җыр барлыкка килде. Әле тамашачыга чыгармадым.

– Ул җырны үзең башкарачаксыңмы?

– Белмим. Салават абыйга бик туры килеп тора. Хәзер тормышымның иң авыр чагы. Әтине югалту авыр булды, 67 яшендә китүенә әле дә ышана алмыйм. Гомере буе шофер булды, бер авария дә ясамады. «Шулмы сөю?» җыры чыккач та, иң беренче әти-әнигә алып кайтып тыңлаткан идем. Әти иҗатым белән бик кызыксынды.

«Әткәй, әнкәй» җырын елыйелый яздырдым. Сизенү булгандыр. «Әти-әни исән чакта кайтып хәлләрен белик» дигән сүзләр бар анда. Истә калсын дип, исән чакларында клип төшерәсем килде.

– Әтиеңне һаман сагынасың икән...

– Әти белән без бик дус идек. Йөзгә дә мин әтигә охшаган. Аллага шөкер, әти-әни янына гел кайтырга тырыштым. Һәрчак бүләкләр белән кайтам. Әтине бер күз карашыннан аңлый торган идек. Машина алып бирергә хыялланган идем дә бит. Әтине сөендерә алмадым...

Әти мине туган якны, туган туфракны яратырга, кадерләргә өйрәтте. Үзе дә читтә яшәгәндә: «Авылны, хәтта лапас исләренә хәтле сагынып кайттым», – дип сөйли иде. Туган якка мәхәббәт темасын иҗатымда һәрвакыт алга сөрәчәкмен. Моны әтиемнең нәзере кебек кабул итәм. Элек үзем дә читтә яшәргә кызыга идем. Хәзер минем өчен авылымнан да якын җир юк. Анда мине әти һаман көтәдер сыман.

– Ирең иҗатыңны аңлыймы?

– Илшат белән өч бала үстерәбез – Самат, Сәйдә, Сафия. Иң олысына 18 яшь тула. Улым тугач, «Мин бит татар малае» дигән җыр язган идем. Аны сораган һәрбер кешегә бушлай җибәрәм. Балаларыбыз шул җырны җырлап, үзләренең татар булуы белән горурланып үссен дигән ният белән.

Аллага шөкер, ирем иҗатымны аңлый. Баштагы мәлләрдә: «Ничек инде җырчы? Балаларны карамый, гастрольләрдән кайтмый йөри башлыйсыңмы?!» – дип гаҗәпләнгән иде. Минем үземә дә бу нәрсә ят. Ниятем андый түгел. Башка шәһәрләргә берике көнгә чыгып керә алам. Бер атнага, айга сузылган гастрольгә чыгып киткәнем юк.

– Фирүзә, балаларыгызга чын татар исемнәре биргәнсез. Кайбер яшьләр татар исемнәреннән оялып, нейтраль яңгырашлы исемнәр кушарга тырыша.

– Без кушканда бу исемнәр сирәк иде, хәзер еш ишетелә. Чын татар исемнәре кушканга горурланам гына. Ничек инде үз милләтеңнән, телеңнән оялырга була? Аңламыйм. Аннары җанисәптә татарларның кимүе дә нык борчуга салды. Балаларга татар телен, мәдәниятен өйрәтергә кирәк, башка чара юк. Татар җырларын тыңлап үссеннәр иде. Аңнарына сеңсен дип, татар җырлары өйдә дә, машинада да өзелми. Җыр – барыбер тәрбия чарасы ул.

Күптән түгел «Балачак җыры» бәйгесендә «Мин татарча сөйләшәм» дигән җырым җиңү яулады. «Татар малае» исемле җырым да бар. Аны Аслан Миргаязов башкара.

– Соло концертлар оештырырга уйламыйсыңмы?

– Мин ул эшне башлаган идем, яңа программа да төзедем. Әти үлгәч, ул программа хәзерге күңел халәтем белән бер дә туры килми. Башкача төзергә кирәк. Аннары күңелгә дә әллә нинди уйлар килә. Без гомерлек түгел. Соңгы вакытта дөньяда барган вакыйгалар да күңелне тынычландырмый. Беләсеңме, мин тормышта нәрсә аңладым? Синең бәхетле булуың синең үзеңнән тора. Менә кияүгә чыгам да бәхетле булачакмын; бала табам, фәлән эшне башкарам да бәхетле булачакмын – әнә шул рәвешле алданабыз. Эш бүген бар, иртәгә юк. Акча да шулай. Адәм баласын Аллаһка ышану, өмет кенә яшәтә. Әчке халәтең белән шуны аңлау, үзеңдә шушы бәхетне тоя белү кирәк.

Эльза ГАЗИЗОВА.

«Әйткән сүз – аткан ук»

●Тукайның Р.Гайнанов төзегән дүрт һәм биштомлыклары.

Бервакыт миңа хәбәр ирешә: Тукай музеенда Тукайга багышланган утырыш булган икән. Халык шагыйре, «Тукай кодексы» авторы Зиннур Мансуровны тыңлаганнар. Шагыйрь совет чорында чыккан Тукай томлыклары турында «каты» сүзләр әйткән, искәрмәләрдә «чәч үрә торырлык, шайтан аягын сындырырлык, бидгать» хаталар тапкан икән. Ләкин нинди хаталар икәнлеген генә әйтмәгән. Шуңа күрә бу «коточкыч» тәнкыйть «беспредметный» хәбәр булып калган. Шул ук вакытта шул совет чорында Тукай турында китаплар язган И.Нуруллин белән Р.Нафиговка рәхмәт әйткән. Азат Ахунов белән Марсель Ибраһимовны «безнең яшь тукайчыларыбыз» дип атаган. «Шундый контраст килеп чыкты», – ди танышым. Шул ук вакытта Рашат Гайнанов төзегән томлыкларда нинди куркыныч хата киткән икән, дип тә кызыксынды.

Әйе, сайланыш юлы белән булса да, элекке тукайчыларның кайберләре модадан төшеп бара икән шул. Хәзерге яшь тукайчылар янында Рашат Гайнанов тоныграк күренә инде. Ул бит гомере буе татарның гарәп язулы барлык газета-журналларын берәмтекләп тикшереп, Тукайның 30 гына тәхәллүсен ачкан, 170 кенә әсәрен ачыклап томнарга кушкан. Тукай гомерендә беренче тапкыр аның әсәрләрен фәнни басма итеп чыгарган – бер томлык искәрмәләр язган...

Шул җыелыштан кулларына репортаж килеп керүгә үк, «Мәдәни җомга»лылар әлеге «коточкыч» хаталар турындагы хәбәргә зур игътибар биреп, мәкаләдән аерып алып, үзләренең «Әйткән сүз – аткан ук» рубрикасында бирергә кирәк тапканнар (6 май, 2022). Бу рубрикада менә нинди сүзләр бар: «Совет чорында бик күп монографияләр эшләнде. Без хәзер шушы чорда барлыкка килгән фәнни хезмәтләрне тәнкыйтьләү-сүтү белән шөгыльләнергә тиеш түгел. Без ул идеология чорын беләбез, әдәбият, галимнәр совет идеологиясенә кертелгән булган. Алар тудырганның яхшысын алып, киләчәккә барырга тиешбез. Совет чорында чыккан Тукайның томлыкларын, аның искәрмәләрен укып карагыз әле – анда шайтан аягын сындырырлык әйберләр, бидгатьлек, гомумән чәч үрә торырлык әйберләр бар. Без бүгенге заман биеклегеннән торып, яңасын эшлик, искәрмәләрнең яңасын языйк».

«Атылган ук» килеп тиде. Ләкин бер миңа гына түгел. Әйтик, Уфадан бер әдип уенын-чынын бергә кушып: «Атылган ук»ны күрдек, «әйтелгән сүз»нең дә нәрсә икәнлеген беләсе килә бит», – диде. Гомумән, Р.Гайнанов төзегән дүрт һәм биш томлыклар белән таныш булган кешеләрне бу хәл кызыксындыра, әлбәттә...

З.Мансуров белән очраклы рәвештә «Татмедиа» фойесында туры килдек. Укучыларны борчып, әсәрләндереп калдырган «каты» сүзләрнең сәбәпчесе – томдагы искәрмәләрнең совет, ягъни динсезлек идеологиясендә язылуы икән. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты текстологлары, зур эш башкарып, Тукайның алты томлыгында (2011-2016) Р.Гайнанов төзегән биш томлыктагы искәрмәләрне «бүгенге заман биеклегеннән торып», совет идеологиясеннән, динсезлектән коткарып чыгарды югыйсә.

Мин З.Мансуровның Тукай томлыклары турында язган мәкаләләрен укып барган идем. Хәзерге күзлектән караганда, ул теге чактагы шәрехләрне дөрес тәнкыйтьли. Дини җәһәттән арттырып җибәрүләрне әйтә. Шулайдыр, атеизм чорында эшләдек бит. Шагыйрь шулай ук аерым шәхесләр турында бирелгән мәгълүматларны да – «намус кагыйдәләре буенча катгый билгеләнгән чик-чаманы санга сукмау, – дип бәяли. – Әйтик, Йосыф Акчура, Һади Атласи, Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Садри Максуди кебек затлар – татар халкының асыл уллары – күп томлыкларны төзүчеләр тарафыннан эшләнгән искәрмәләрдә ничек кенә тамгаланмады: кадет, либераль буржуа идеологы, буржуаз тарихчы, буржуаз милләтче әдип... Гүя ки боларның бөтенесе дә КГБ досьесыннан алынган». Шәп әйтелгән сүзләр. Тик З.Мансуров узган гасырның сиксәненче еллар башында «намус кагыйдәләре буенча катгый билгеләнгән чик-чаманы санга сугып», бу шәхесләр турында ничек язарга кирәк булганын гына әйтми. Бәлки, бу тәнкыйть сүзләрен ул елларда, күптомлыклар чыккан чорда ук язарга кирәк булгандыр. Эффекты зуррак булыр иде... Ә хәзер без барыбыз да акыллы. «Теге яктагылар»ны теләсә кем ничек тели, шулай гаепли ала.

Бер мисал. Биштомлыкның өченче том искәрмәләрендә Р.Гайнанов Г.Исхакый турында киңрәк мәгълүмат биргән иде. Тиз генә редколлегия утырышын үткәрергә кирәк булды (Редколлегия әгъзалары: Ш.Асылгәрәев, Ш.Галиев, Р.Нәфигов, С.Хәким, Г.Халит, Н.Юзеев). Томнарны әзерләшүче буларак, утырышта мин дә катнаштым. «Исхакыйны болай пропагандаларга ярамый! Шулай басылса, Көнбатыш күреп, язып чыкса, безнең органнар ни әйтер?» – сүз шул турыда барды. С.Хәким сүзләрен язып куйганмын: «Г.Исхакыйның олы язучы икәнлеген киләчәк буынга без әйтмәсәк, кем әйтер? Шул ук Көнбатыш әйтерме? Ул бит инде, әйтсә, үзенчә әйтер». Өченче томнан Исхакый турындагы байтак сүзләр сызылды, «Исхакый – буржуа әдибе. Бу вакытта ул татар эсерлары органы – «Таң йолдызы»нда эшли», – дигән сүзләр генә калдырылды.

Томлыкларны Гали Халит редакцияләде. Нәшрияттагы Главлитка кадәр Тукай буенча ИЯЛИдә иң «сизгер» цензор ул иде. Фәлән текстны томнарга кертү-кертмәү мәсьәләсендә төзүче белән бәхәсләшә дә иде. Мәсәлән, «Туган тел»нең дүртенче – «дини» куплеты да алдагы томлыкта чыккан иде инде.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:

Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәмәнкәмне, Ходам!

Әмма биштомлыкка җиткәч, редактор нигәдер шикләнгән. Без утырган бүлмәнең уртасында Рашат абый белән икесенең бәхәсләшүенә шаһит булдык. Гали абый әйтә: «Инде без бөек Тукайны Ходай алдында тезләндереп ялвартабызмы?» Рашат абый әйтә: «Юк, без ялвартмыйбыз, Тукай үзе ялвара». Дүрт һәм биштомлыкны да редколлегия дә, нәшрият редакторы да, Главлит та сүз әйтмичә үткәрде. Ә менә мөхтәрәм З.Мансуровның «совет идеологиясендә» чыккан күптомлыкларны 35 елдан соң кызу тәнкыйть утына тотып язган мәкаләләрен ул чорда беркайда да басмаслар иде... Бәлки, әле КГБ да кызыксыныр иде... Чоры нинди – таләбе шундый.

Тагын бер мисал. Марсель Әхмәтҗанов белән без Такташның бер генә том булып чыгып килгән иҗатын өч томга җиткердек. Шагыйрьнең Милли музейдагы архивында саклаган гарәп язулы кулъязмаларыннан күтәреп, мин прозасын, публицистикасын әзерләдем, М.Әхмәтҗанов көндәлекләрне, хатларны эшләде. 1983 елда чыккан бу өчтомлыкта Мирсәет Солтангалиев турында «татар контрреволюцион буржуа милләтчеләренең җитәкчеләреннән берсе», – дип яздык. Нәкъ тарихчылар язганча. 27 елдан соң без Такташ өчтомлыгының «төзәтелгән, тулыландырылган» басмасын әзерләп чыгардык (2010). Монысында М.Солтангалиев турында болай яздык: «күренекле дәүләт эшлеклесе, милли дәүләт төзү теоретигы». Нәкъ хәзерге энциклопедиядәгечә. Хәзер кулыбызда шул «төзәтелгән» басма була торып, «нигә теге вакытта милләтнең асыл затларына шундый ярлык тактыгыз» дип, безне табаларга кирәкме?

Ул чорларда дини, сәяси булмаган мәсьәләләрне дә үткәрү мөмкинлеге юк иде... Шактый озак туктап торганнан соң, 1958 елда, кабат чыга башлаган «Азат хатын» журналында Рашат абый җаваплы секретарь иде. Ул, һаман элекке газета-журналларны өйрәнү белән мәшгуль булып, Тукай, Әмирханнар «дөнья»сында яшәп, онытылган татар сүзләрен матбугатка кабат кайтарырга тели иде. Һәм ул, журналда «төп скрипка» булуыннан файдаланып, кулланышта булган рус сүзләрен татарчага әйләндереп яза башлады. Минем «Социалистик Татарстан»да эшләгән чагым. Көн саен Шәмси Хамматов янына бер сәгатьлек «пятиминутка»га җыела торган идек. Берсендә Зәйни абый Төхвәтуллин: «Азат хатын»ның соңгы номерын күрдегезме әле? Тагын Гайнановның комган теле белән чыккан», – диде. Хихылдап куючылар да булды. «Комган теле»нә нинди сүзләр керә иде соң? Рәис, нәшрият, идарә, әгъза, рәссам, гаилә, сан, кат, мәдәният һ.б. Әләкләр булып, журналның редакторы Асия апа Хәсәнова белән Рашат абыйны КПССның өлкә комитетына келәмгә чакырып «өшкергәннән» соң, журнал «акылга утырды»: тагын председатель, издательство, управление-правление, член, художник, семья, номер, этаж, культура дип яза башлады.

Якташыбыз Әнгам Атнабаев шигыре искә төшә:

Ник талантлы якташларым
Казаннарга китеп торып кала?
Казаннарда татар булу җиңел,
Уфаларда татар булып кара.

Шул шигырь мотивына ияреп бер «ак» шигырь:

Үз акылыңны җигү хәзер җиңел булса,
Үткәннәрне тәнкыйтьләргә җайлы булса,
Акылыңны тыеп, башың иеп,
Өстән төшкән акыл белән яшәп кара...

Үз заманында Р.Гайнанов төзеп чыгарган күптомлыклар җәмәгатьчелектә уңай бәя алды. Галимнәр искәрмәләрдә бөтенләй башка кыйммәтләргә игътибар итә иде. Дүрттомлык чыгуга, аны тикшерүгә куйдылар. Мөхәммәд Мәһдиев үз чыгышында болай ди: «Тукай томнарын арткы яктан укый башладым, искәрмәләрдән. Һәм аерыла алмыйча укып чыктым. Бу бит кече бер энциклопедия! Никадәр информация. Тарихтан, әдәбият белеменнән, безнең элекке, иске газета-журналлардан күпме белем, күпме мәгълүмат!.. Дәрәҗәле исемнәре, бүләкләре дә булыр Гайнановның, мәсәлән, Тукай бүләге. Рашат Гайнанов без белмәгән күпме яңа әсәрләрен тапкан, әле күбесе томга кермәде», – ди. Нәкый Исәнбәт: «Элекке томнарда булмаган материалларны кертеп, Рашат Тукай мирасын баеткан... Аңлатмалары башка басмадагыларга караганда күп өстен. Күпме яңа ачыш, яңалык, бик күп белем. Эзләнү, эшләү нәтиҗәсе бу. Бик күбесен хәтта мин дә белмим, ул миннән күбрәк белә. Тукайның ритмикасын төзекләндерү ягыннан да Рашат бик күп эшләгән. Тукайча дөрес итеп саклау ягыннан бик зур өлеш керткән. Бу мәсьәләдә ул башка басмалардагы күп хатаны төзәткән. Тукайның биш томлыгын эшләргә планлаштырасыз икән, Рашаттан башка Тукай буенча белемлерәк кешене күрмим бүгенге көндә. Системалы итеп эшли белә, аңлашылып тора, материаллары да бихисап».

С.Хәким: «Р.Гайнановның Тукай әсәрләренә язган искәрмәләре үзе бер фәнни диссертация!» – дип язды. Раиф Мәрданов: «Ул татар әдипләренең күптомлыкларын төзүнең эш принципларын һәм системасын булдырган галим... Сокландыргыч дәрәҗәдә фәнгә бирелгән, шуның белән яши торган, уникаль хәтергә ия зур галим иде». Марсель Әхмәтҗанов: «Милли мираска тискәре мөнәсәбәт хакимлек иткән илдә Г.Ибраһимов һәм Г.Тукайларның академик басмаларын әзерләүгә керешкән татар текстологына кимендә академик дәрәҗәсе бирү кирәк, дип саныйм... Рашат ага 1986 елда институттан китте. Инде ул төп эшне эшләгән, татар әдәбиятының текстологиясен югары фәнни дәрәҗәгә күтәргән иде». Миркасыйм Госманов Р.Гайнановны «энциклопедик галим» дип язды, җәсәде янында башын иеп: «Йөз елга бер килә торган галимне саклап, озаграк яшәтеп, эшләтеп кала алмадык», – диде.

Рашат абый, бик күп рәнҗетүләр күреп, 65 яше дә тулмыйча, йөрәк өянәге белән вафат булды. Үлеменнән соң да рухын рәнҗетү дәвам итә. «Тукай энциклопедиясе»нә Рашат абый турындагы мәкаләне Ф.Галимуллин язган иде. Зөфәр Рәмиев, автор белән дә санлашмыйча, ул мәкаләне тунаган һәм Р.Гайнановның фотосын да бирмәгән. Энциклопедиядә 200 кешенең фотосы урнаштырылган. Шул 200 кешенең һәркайсы, шул исәптән Рәмиев үзе дә, «Тукай буенча минем эшем Гайнановныкыннан зуррак» дип әйтә аламы? З.Рәмиев Рашат абыйга карата кылган бу явызлыгын ничек аңлата икән?

Ф.Галимуллин үзенең «Мәдәни җомга»да басылган (21 апрель, 2017) «Энциклопедияле Тукаебыз» дигән мәкаләсендә болай язган иде: «Тукай иҗатын татар, рус, дөнья укучыларына ирештергән, аның шәхесенә һәм иҗатына зур бәя биргән китаплар, монографияләр, картиналар язган күренекле шәхесләрнең фотосурәтләренә йөз елларга бер чыгарыла торган әлеге энциклопедиядә урын табылмавы күңелне борчый... Шулай да портретлары бирелмәгән шәхесләр арасыннан Р.Гайнанов турында аерым әйтәсе килә. Ул, дөресен әйткәндә, Г.Тукайга багышланган энциклопедия рәвешендәге эшне чын-чынлап башлап җибәргән галим. Дүрттомлык һәм биштомлыкларын төзегәндә (бигрәк тә соңгысын), нәкъ менә ул Тукайга мөнәсәбәтле бихисап мәгълүмат туплады. Әгәр 1975-1977 елларда басылган дүрттомлык ун елдан биш том булып чыккан икән, бу – әлеге фидакярьбезнең табышы нәтиҗәсе. Кулыбыздагы энциклопедиядәге күп кенә мәгълүматларның нигезендә дә ул кулланышка керткән фактлар ята».

Лена ГАЙНАНОВА.

«Дәүләткә торырлык өтер»

Шагыйрь Зиннур Мансуровның бер мәкаләсе шулай атала. Ул анда Тукайның «Китмибез» шигырендәге бер бик мөһим юл Р.Гайнанов төзегән күп томлыкларда ялгыш бирелгән, ди. Биштомлыкны әзерләгәндә, Тукай әсәрләрен төп нөсхәләр белән чагыштыру эше миңа йөкләнгән иде. Минем әйтәсе сүзләрем дә нигезсез булмасын өчен, Тукайны төрмәгә утырта язган бу шигырьне бергәләп укып карыйк әле.


٢٤
Если лучше вамъ,
туда сами пожалуйте, господа!

● «Китмибез!» шигыреннән өзек.

Китмибез!
Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
– Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! – диләр.
Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.
Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар – шул иске камчы, башкалык – тик фәсләре!
Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!
Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?
Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз,
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарымыз.
Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәнребез (Гыйззе вә Җәл).
Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!
*Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ!**
Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
– Если лучше вам,
*Туда сами пожалте, господа!***

**Гөрүһе русияһ* – кара йөз димәктер (фарсыча) (Г.Тукай искәрмәсе).
***Сезгә яхшырак булса, үзегез шунда рәхим итегез, әфәнделәр.*

Тәклиф итү – катгый рәвештә тәкъдим итү.
Сәкарь – тәмуг.
Әмсар – шәһәрләр.
Әгъсар – гасырлар буенча үткән еллар.
Гыйззе вә Җәл – кодрәтле һәм шанлы.

Бу шигырьнең язылу тарихын, аңарчы булган фаразларны юкка чыгарып, беренче булып дөрес аңлатучы Р.Гайнанов булды: «Шигырь Дәүләт думасындагы уң депутатларның мөселманнарга карата: «Әгәр сезгә Россиядәге тәртипләр ошамаса, Төркиягә китегез!» дигән провокацион чыгышларына каршы язылган. Дәүләт думасының 1907 елның маенда булган унбишенче мәҗлесендә, мәсәлән, Уфа губернасыннан сайланып килгән депутат мөгаллим Кәлимулла Хәсәнов (1878-1949) мөселман мәктәпләренең хәле начарлыгыннан, хөкүмәтнең моңа бер чара да күрмәвеннән зарланып сөйли. Суллар кул чаба, ә уңнар (Пуришкевич, Созонов һ.б. карагруһлар), урыннарыннан торып, йодрыкларын төйнәп, ораторга ташланалар һәм «Төркиягә китегез!» – дип кычкыралар... Тукай бу шигырендә Россиядәге деспотизмны да, Төркиядәге деспотизмны да фаш итеп, азат Россия идеясен яклап чыга».

Бу катлаулы тоелган мәсьәләне укучыга аңлаешлы итеп чишеп бирү өчен, башта З.Мансуров мәкаләсеннән өзекләр бирик: «Гәрчә үзәккә Дәүләт думасындагы гауга алынса да, төп тема әсәрнең тукымасында беркадәр тармаклану кичерә, – ди автор (Ягъни Тукай үз халкы мәмләкәтенең хөрлеге турында да, Россиянең хөрлеге турында да әйтә булып чыга – **Л. Г.**). «Иң әүвәл шагыйрьнең 1955-1956 елларда дөнья күргән дүрттомлыгын, аларны әзерләүдә кулланылган кайбер принципларны искә төшереп үтик. Андагы текстларның күпчелеге автор тарафыннан карап чыгарылган басмаларның соңгысыннан алынган (кайсы басма – соңгысы? – **Л. Г.**), тыныш билгеләре әдәби телебезнең заманча кагыйдәләренә мөмкин кадәр яраклаштырып куелган. Аннан соңгы дыелмаларында исә «хөр мәмләкәт» белән «хөр Русия» арасындагы өтер сызыкка алыштырылган, нәтиҗәдә тирән эчтәлекле шигъри фразаның татар халкына мөнәсәбәтле фикри өлеше бөтенләй юкка чыккан. Гүяки Г.Тукай әлеге җөмләдә бердәнбер максатын белдерә, ягъни Россиянең азат ил-дәүләт рәвешендә яши башлавын тели. Ай-һай, күңеленә тәүге уй-гамь салынганнан бирле милләт авыруы белән сырхаулаган зат бу очракта һәрдаим сызлаган ярасы турында онытып җибәрер иде микән?! Аннары империягә бәйсезлек дәгъва итүе гайре табигый гамәл була түгелме? Киресенчә, башында самодержец торган монархистик хөкүмәт башка халыкларны ирексез хәлдә калдырган Рус дәүләте оешуга 1150 ел тула. Аны хөр мәмләкәт итеп күрергә ымсыну, валлаһи, мантыйк ягыннан бик сәер килеп чыга»... «Шагыйрь әсәрләренең 1955-1956 елларда басылган дүрттомлыгы, инде әйтеп үткәнемчә, «Китмибез!» шигыренең җиренә җиткереп бирелүе белән аерылып тора. Анда әлеге дә баягы тыныш билгеләре тел кагыйдәләренчә куелган, аларның төп интонациясен дөрес рәвештә чагылдыруга хезмәт итә. Шактый озын-озак тәнәфестән соң, ягъни 1975-1976 һәм 1985-1986 елларда дөнья күргән күптомлыкларда исә бу шигырьнең мәгълүм юлы мәгънәви яктан бозылуга дучар булган. Күптән көтеп алынган өр-яңа академик басмада да «хөр мәмләкәт» һәм «хөр Русия» сызык аша язылган... «Их, икеләнергә сәбәп калмас иде, әмма «Китмибез!»нең кульязмасы сакланмаган... Өтерне сызыкка алыштырып куегыз, дип, Мәскәү күрсәтмә бирмәгән. Үзебез дә оста. Кабатлап әйтәм, кычытмаган җирне кашырга безгә генә куш. Бу эштә һәммәсеннән уздырып җибәрәбез. Дәүләткә торырлык өтер мәсьәләсендә дә кайбер галимнәребез сәяси уяулык күрсәткәндер» (З.Мансуров. Дәүләткә торырлык өтер. Китапта: Дөреслек икегә төрләнмәс. 2018, Казан).

Шагыйрь З.Мансуров теленең үткенлеген һәм алынган мәсьәләсендә укучыны ышандыру осталыгын таныган хәлдә, аның башкаларга карата бик таләпчән булып та, үзенең дә игътибарсызлыгыннанмы, әллә шагыйрьләрчә артык хыялга бирелеп, мавыгып китүе аркасындамы, зур сүзләргә сәбәпче булган ялгышларын күрмәве сизелә.

Сүз әлеге өтер белән сызык хакында. Мәкалә авторы игътибарга алган 1955-1956 елгы дүрттомлыкта «Китмибез!» шигырендә «хөр мәмләкәт, хөр Русия» сүзтезмәләре арасына чыннан да өтер куелган (Төзүчеләре Якуб Агишев, Хәй Хисмәтуллин). Ә шул ук авторлар төзегән 1943-1948 елгы икетомлыкта «хөр мәмләкәт – хөр Русия» дип, сызык куелып бирелгән. 1946 елда Я.Агишев белән И.Пехтелев язган «Габдулла Тукай. Библиографический очерк» дигән китапта шигырьнең без кызыксына торган өлешендә ике арада сызык куелган. Шулай ук 1961 елда Я. Агишевның «Габдулла Тукай» дигән брошюрасында «хөр мәмләкәт, хөр Русия» дип, ике арага тагын өтер куеп язылган. Ягъни бер үк автор «хөр мәмләкәт» һәм «хөр Русия» сүзтезмәләре арасына 2 тапкырында өтер, 2 тапкырында сызык куеп яза. Бу нәрсә турында сөйли соң? Димәк, авторлар сызык белән өтер арасында аерма күрмәгән, тыныш билгеләренең төрлечә куелулары аларның хәтердән генә язылуыннан килгәндер. Шунысына да игътибар итәргә кирәк: З.Мансуров иң дөрес эшләнгән дип атаган әлеге 1955-1956 елгы дүрттомлыкта «Китмибез!» шигыренә бирелгән искәрмәдә «Тукай азат Россия идеясен яклап чыга», диелә.

Үзен хөрмәт иткән текстолог, авторның һәр әсәре өстендә эшләгәндә, мөмкин булганча моңа кадәр чыккан басмаларның барысын да карап чыгарга тырыша. Әлбәттә, автор яшәгән чорда басылганнарын аеруча игътибар белән тикшерә. З.Мансуров Тукайның үз китапларын соңгы корректурасына кадәр үзе тикшереп чыга торган булган, дип дөрес яза. Шундый китапларның берсе – Тукайның үз кулы белән төзелгән, 1907 елда басылып чыккан «Шигырьләр көтепханәсеннән, 4 нче дәфтәр». Нәкъ шул «Китмибез!» шигыре басылган китап. Ул китапта шигырьнең без тикшерә торган юлын Тукай «хөр мәмләкәт – хөр Русия» дип, ике сүтезмәне сызык аша бирә. Димәк, Р.Гайнанов төзегән күптомлыкларда бу дөрес бирелгән, шигырьгә искәрмә дә дөрес язылган. Димәк, «дәүләткә торырлык өтер» дә юк!

Шунда «чәчләр үрә тора» торган мәсьәләгә нокта да куеп булыр иде. Тик шуны әйтәсе килә: «Китмибез!» шигыренең («өтер» беләнме анда, «сызык» беләнме) өстәмә йөкләмәсе юк. Татар мәнфәгатен дә күздә тотмаган дип, Тукайны да гаепли алмыйбыз. Бу шигырьдә сүз бары тик Төркия белән Россия турында гына бара. Ә шагыйрь: «Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия», – ди икән, без, татарлар да, яшәгән Россиянең хөр булуын телибез, ди. Россия хөр булса – халыклары да хөр була, дигән сүз. Әлегә кадәр тулы хөрлеккә ирешә алмаган Россиядә яшибез бит...

Тукай өчен уйлап, аңа үз фикеребезне тагып, З.Мансуров әйтмешли, кычытмаган җирне кашып, юк җирдә бәхәсләр кузгатып, «каты» сүзләр белән Тукай иҗатын сөючеләрне аптырашта калдырмасак иде.

Шулай да... «Татмедиа» фойесындагы әңгәмәбез ахырында З.Мансуров моннан дистә еллар элек интернетта язган сүзләрен кабатлады: «Тукай буенча Рашат Гайнанов башкарган титаник эшне башка беркем дә башкара алмый».

Лена ГАЙНАНОВА.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

18 март (шимбә). ***Шәгъбән аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 6.18 сәгатьтә калка,13.42 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 11.59 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Табигать дәвалый

Грипп вакытында хәлне җиңеләйтү өчен, 1 әр аш кашыгы юкә чәчәге һәм балан җимешен кушып, өстенә 2 стакан кайнар су коялар, кайнатып чыгарып, сүрән утта 10 минут пешерәләр, сөзәләр, төнгелеккә кайнар килеш 1-2 чынаяк эчәләр. Яисә 1 аш кашыгы кипкән кура җиләген 1 стакан кайнар суга салып, 20 минут төнәтәләр дә, кайнар килеш, көненә 2 тапкыр 1 әр стакан эчәләр. 1әр аш кашыгы карлыган, кура җиләге, гөлҗимеш өстенә 100 мл кайнар су салып, 15 минут төнәтәләр, 1 аш ашыгы бал кушалар, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, яртышар стакан эчәләр. Яки сарымсакны вак угычтан уып, шулкадәр үк бал кушалар да, кич йокларга ятар алдыннан 1 аш кашыгы кабып, артыннан кайнаган су эчәләр.

19 март (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 27нче көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 6.34 сәгатьтә калка, 15.21 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.03 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Теш сызлаганда

Сызлаган тешкә чи чөгендер телеме, ат кузгалагы яфрагы яки бака яфрагы тамыры куйсаң, авырту басыла. 1 аш кашыгы шалфейны 1 стакан кайнар суда 1сәгать төнәтәләр, көненә 3 тапкыр 1әр аш кашыгы эчәләр, шуның белән әледән-әле авызны чайкыйлар. Яисә тигез микъдарда суган, сарымсак һәм тозны кушалар, яхшылап изәләр дә, шуны сызлаган тешкә куялар, өстеннән мамык тампон ябалар.

20 март (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 6.46 сәгатьтә калка,16.56 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.08 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

21 март (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 29 нчы көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 6.55 сәгатьтә калка, 18.27 сәгатьтә бата. 20 сәгать***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Мәдәни җомга
17 март
№10, 2023

23 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 12.12 сәгать.

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Витаминлы катнашма

Язын, хәлсезләнгән организмга булышу өчен, мондый катнашма белән дәвалану файдалы. 200 әр г инҗир, йөзем, күрәгә, мүк җиләге, кара җимеш, әстерхан чикләвеге, 2 лимонны иттарткычтан чыгарып, 200 грамм бал кушалар да, көненә 3 әр аш кашыгы кабалар.

22 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 30 нчы көне. 1, 2 нче Ай тәүлекләре. Ай Кучкар йолдызлыгында, 7.04 сәгатьтә калка, 19.56 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.17 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

23 март (пәнҗешәмбе). ***Рамазан аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 7.13 сәгатьтә калка,21.24 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.22 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Прополис сихәте

Гаймориттан котылу өчен, 1 чәй кашыгы вакланган прополисны 3әр чәй кашыгы йомшартылган атланмай белән көнбагыш маена кушып болгаталар да, шуңарда 2 мамык кисәген чылатып, иртән һәм кичен борынга куялар.

24 март (җомга). ***Рамазан аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 7.21 сәгатьтә калка, 22.52 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.26 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмләрәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк.

Үрмә икмәк (хала)

Бик йомшак ике икмәк килеп чыга. 210 г җылы суга 30 г шикәр, 8 г коры чүпрә салып болгаталар да, ике йомырка сытып, яхшылап туглыйлар, 40 мл көнбагыш мае, 1 чәй кашыгы тоз, 550 г он кушып, камыр басалар, өстен каплап, җылы урында 1 сәгать кабарталар. Аннары сигез тигез өлешкә бүлеп, һәркайсын озынчалап җәяләр, катлама кебек төреп, әвәлиләр дә, шул “бау”лардан матур итеп дүртле толымнар үреп (башкача үрергә дә була), ике икмәк ясыйлар. Өстен каплап, ярты сәгать кабарталар, тугланган йомырка белән “майлыйлар”, булса, көнҗет сибәләр дә, 180 градуслы мичтә 35-40 минут пешерәләр.

Чигү остасы

«Бәхетле буласың килә икән, кулыңны эшле ит, акылыңны максатка җик, хәтереңне файдалы мәгълүмат белән генә бает, йөрәгеңне ярату, сөю белән тутыр, киләчәккә өмет белән кара!» Әлеге акыллы сүзләрне 9 бала анасы Бибигафия әби белән Әхмәтгаян ага Мөхәммәтхановлар кызы Гөлсинә апа Мәхмүтовадан ишеттем. Бибигафия әби, гомере буе колхозда эшләп, соңгы ун елында сукыр калгач та, тормыш иптәше Әхмәтгаян ага белән балаларына тәпле белем һәм тәрбия биреп, Мамадыш районының Югары Яке авылында гомер иткән. Балаларга кечкенәдән милли рух сеңдерелгән. Нәселләре бик дини, әниләре Бибигафия апа авыл абыстае булган. Мөхәммәтхановлар балаларын кечкенәдән мөстәкыйльлеккә өйрәтеп, аларны иманлы мөселман итеп үстерүне, кешеләрне рәнҗетми, булдыра алган кадәр ярдәм итеп яшәүне максат итеп куйган. Кызлары Гөлсинә, Зәкия, Гүзәлия кечкенәдән үк татар халык йолалары, гореф-гадәтләре белән кызыксынган. Олы кызлары Зәкия бәйләүгә оста булса, Гөлсинә чигү белән шөгыльләнгән. Әниләре: «Төнге эш – табыш ул», – дия торган булган. Кызлар кич бүе шәл бәйләп, сату өчен әзерләгән. Акчасына тукыма, мулине җепләре алып, чигүне дә өйрәнгәннәр. Кызларның, тормышка чыкканчы, барлык бирнәләре дә – бизәкле, хәтта аяк чолгаулары да чигүле булган. Гүзәлия дә, апаларыннан күреп, чигешләр белән нәкышләп бирнә хәстәрләгән.

Кызларны кәсепләре гомер буе озатып барган. Болын-урманнардагы чәчәкләр, табигать матурлыгы – барысы да тукымага төшкән. Әтиләре – урманчы, ул һәр агачның үзенчәлеген, чыдамлылыгын белә, төрле зурлыктагы киергеләрне дә ясап бирә. Шулай итеп, кызлар бик оста чигүчеләргә әверелә: алар кул эшенең атлатып чигү, шома чигү, тамбурлы, әвернә чигү кебек алымнарын үзләштерә.

Гомер уза. Кызлар шәл бәйләми инде. Ләкин чигү сәнгате белән бүгенге көндә дә мәшгуль. Гөлсинә, Зәкия апалар, район, республика күләмендә узган чараларда оештырылган күргәзмәләрдә чигешләре белән катнашып, халыкны матурлык белән хушландырып, осталык дәресләре уздырып, халкыбыз тарихы турында мәгълүматлар биреп кайта. Бу көннәрдә Гөлсинә апа Әхмәтгәрәева тәрәзә төбендә үскән яран гөле чәчәкләрен тукымага төшерә, өстәл ашъяулыгы чигә. Бакыйлыкка күчкән Зәкия апаларының 3баласы Арташ авылындагы өйләренә юлны өзми, әниләре чиккән япмаларны истәлек итеп саклый.

Кече сеңелләре Гүзәлия Гобәйдуллина апаларыннан да остарак булып чыкты: аның матур чигешләре – бихисап! Иҗат җимешләре белән күп еллар район Сабан туенда, Питрау бәйрәмнәрендә «Авыл өе»н бизи. Казан халкы, чит ил кунаклары «Дөрестән дә, кул эшеме бу?» – дип гаҗәпләнә, фотога төшерә. Гүзәлия Әхмәтгаян кызы, 2011 елның декабрь аенда Россия ислам университетында уздырылган «Энҗе» I республикакүләм кул эшләре бәйгесендә катнашып, утыздан артык оста арасында «Королева хенд-мейд» исемен яулады. 2014 елда Казан шәһәре милли мәдәни үзәгендә Татарстан мөселман хатын-кызлар берлегенең республикакүләм корылтаенда уздырылган «Ел мөслимәсе» бәйгесендә чиккән ядкәрләре диплом һәм приз алуы барыбыз өчен дә сөенечле вакыйга булды. Аның чигешле иҗаты Магнитогорск, Троицк, Чиләбе өлкәләрендә үткән сабан туйларында да дипломнар, бүләкләр белән бәяләнде. Гүзәлия Гобәйдуллина ТНВ каналында «Аулак өй» тапшыруында да чигешләре белән катнашты. 41 ел буе Мамадыш үзәкләштерелгән китапханәсенең китапларны туплау һәм эшкәртү бүлеге белгече, 2 бала анасы, мәдрәсәдә укып, дини белемен арттырырга да вакыт таба. Шул ук вакытта ул – «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының район бүлеге активисты да.

2022 елның август ае Гүзәлия һәм аның ире Нургали Гобәйдуллиннар өчен шатлыклы көннәр булып хәтердә калды: алар яңа өйгә күченде. Шушы йортта Гүзәлия музей оештырырга хыяллана һәм бу теләген тормышка да ашыра. Музейда балалар, өлкәннәр өчен районның «Ак калфак» оешмасы белән берлектә очрашулар, осталык дәресләре үтә. Укучы балалар Гүзәлиянең халкыбыз көнкүреше, тарихы турында сөйләвен тыңлый, чигеш бизәкләренә соклана. Ә өлкәннәр үзләренең яшьлек елларын искә алып, рәхәтләнеп хатирәләр белән уртаклаша.

Бибигафия әби кызлары бүген бәхетле гомер кичерә. «Бәхетле буласың килә икән, кулыңны эшле ит!» – дип тикмәгә генә әйтмәгән бит Гөлсинә апа. Сөлге, мендәр тышлары, ашъяулык, табын япкычлары, кулъяулыклар чигү, үзенчәлекле читек-башмаклар, урындык япмалары бәйләү – аларга бәхетле гомер итүдә төп булышчы булган, шушы матурлыкны үз тормышларын да ямьләндергән.

Луиза МИСБАХОВА.

Мамадыш районы.

Мәңгегә хуш инде...

«Кеше гомере ике каш арасындагы аралык кебек кенә», диләр иде, дөрес икән. Быел абыебыз Василга да 65 яшь тулган булыр иде. Әмма ул йөрәк өянәге белән арабыздан кинәт китеп барды.

Ул безнең гаиләдәге биш баланың өченчесе иде. Мәктәптән соң авыл хуҗалыгы институтын тәмамлады. Совет армиясе сафларында, Кытай чигендә хезмәт итеп кайтты. Аннары колхозда баш агроном, унбиш еллар чамасы КамАЗның двигательләр заводында бригадир, кабат туган мәктәбендә химия укытучысы, колхоз бригадиры, ашламалар белән җир ашлау белгече... Лаеклы ялга чыккач та ял белмәде, хуҗалыкта терлекләр карый, күршеләргә ярдәм итә иде.

Ул гомер буе җыр яратты, аның җырлавын Таһир Якупов тавышына охшаталар иде. Өебез каршына гаярь нарат, миләш агачлары утыртты, үзе дә алар матурлыгы белән хозурлана иде...

Хәзер дә туган авылыбызга бик сагынып кайтабыз. Өй эче буш сыман. Ләкин күңел буйсынмый, юксына бит: әтиебез урынына калган Васил абыебыз да ишегалдына кайтып керер төсле...

Сөмбелә ГАЛИМУЛЛИНА.

Игелекне кемгә кылырга?

Мәдрәсәдә остаз шәкертләргә шундый сорау биргән:

– Без кешеләргә яхшылык кылу турында күп сөйләштек. Хәзер үзегез кешеләргә яхшылык эшләүне күрсәтегез, – дигән.

Каникулдан соң, хәзрәт шәкертләрдән җавап сораган.

– Мин картларга булыштым. Аларның һәрнәрсәгә көче җитми, – ди берсе.

– Мин авырулар карадым, чөнки алар ярдәмгә мохтаҗ, – ди икенчесе.

– Мин ярлыларга булыштым, – дигән өченчесе.

– Мин балаларны якладым. Алар зурлар тарафыннан яклауга мохтаҗ, – дигән дүртенчесе...

– Мин һәр кешегә дә игелек кылырга тырыштым. Мөгаен, мин ялгышканмындыр, – дигән соңгы шәкерт.

Һәр кешегә игелек кылырга кирәк, аерым берәүгә генә түгел, – дигән остаз һәм соңгы шәкертне мактаган.

Авыл мәчете янында

«Бүген мәчет янына акыл иясе килә», – дигән хәбәр авылда тиз таралды. Андый вакыйга һәр көнне булып тормый. Диниман бик зәгыйфь булса да, кешеләр шактый җыелды. Алар арасында күбесе яшьләр иде. Күп сорауларга җавапларын акыл иясеннән сорарга булдылар, чөнки авыл имамының абруе бик түбән иде. Аллаһ Тәгаләнең юклыгы турында сөйләп йөргән яшьләр бу акыл иясеннән көләргә ниятләде.

– Сез бөек Аллаһ дигән зат кайда яшеренгән, ул кайда яши? – дип беренче сорауны бирделәр остазга.

– Сез миңа бер стакан сөт китерегез әле, – диде остаз җавап көтүчеләргә.

Аңа бер стакан сөт китереп биргәч, ул стакан тоткан кулын астан да, өстән дә, яннан да игътибар белән карый башлады. Җыелган халык та кызыксынып, аның нәрсә эзләвен белергә теләде.

– Барлык кешеләр дә сөттә май бар, дип әйтәләр, шуны күрәсем килгән иде, – ди остаз.

Акыл иясенең мондый хәленнән, бигрәк тә яшьләр, кычкырып көлә башладылар.

– Шулкадәр надан, томана адәм икәнсең! Сөттә май бар икәнлеген юләр кеше дә белә. Аны күрер өчен башта сөтне язырга кирәк. Моның өчен аны бик яхшылап болгатырга, әйрәнен чыгарырга, майны җыеп алырга кирәк, – диделәр.

– Шулаймыни әле ул, – диде остаз, – алай булса, Аллаһның кайда икәнлеген сезгә аңлату җиңеләя. Ул бөтен җирдә бар, аның рәхмәте белән без бу җирдә яшибез. Әмма аны күрү, тою өчен аның кушканнарын үтәргә, ә ул тыйганнардан тыелырга кирәк бит. Менә шул очракта гына соңыннан шәфкатен, нигъмәтләрен тоя башлыйсың һәм Аның нигъмәтләре бөеклеген танысың.

Җыелган кешеләр акыл иясеннән:

– Нигә мәчеткә кешеләр бик аз йөри? – дип сорады.

– Бер чиләк су китерегез әле, – дип сорады остаз, аннан дәвам итте, – менә бу чиләктәге су – мәчеткә йөрүче мөселманнар, – диде һәм чиләктәге суны түгеп, аны яңадан утыртып куйды. Бераздан тагын чиләкне алып җыелган суны түкте. Аннан нибары биш-алты тамчы су агып чыкты.

– Менә соңгы тамчыларны күрәсезме, – болары мәчеткә килеп, гыйбадәтләрне башкарып, Аллаһ аларның гөнаһларын ярлыкаган кешеләр. Күп кешеләр мәчеткә «оныгын институтка кертүне», «кызын күп акчалы эшкә урнаштыруны», «байлык табарга булышуны» сорап дога укытырга килә.

– Йә, Раббым, гөнаһларымны ярлыка, миннән разый булсаң иде, – дигән сүзләрне мәчеткә килгәннәр әйтмиләр, тәүбә кылмыйлар, кешеләр йөргәнгә генә баралар, нигә килгәннәрен дә белмиләр, Аллаһ йортына баруның сәбәбен-максатын аңласалар, мәчеткә йөрүче артыр иде, – дип тәмамлады сүзен акыл иясе.

Әниләр башкача уйлый

Бер карт белән яшь кеше кое янына басып сөйләшә иде. Аларның әңгәмәсе бәхәскә әйләнде: кайсыбыз кешеләрне яхшырак аңлый? Шул вакыт алар янына бер әби килеп:

– Сезнең яннан озын буйлы, төз гәүдәле, матур гына егет узып китмәдеме? – дип сорады.

– Ул елга буена төшеп китте, – диде шунда ук карт кеше.

– Әмма безнең яннан бөкрәйгән бабайга охшаганрак кеше үтеп китте бит, – диде яшь кеше соңыннан. Карт үзе белән бәхәсләшкән егеткә:

– Син дөрес әйтәсең, әмма ул хатын үзенең улы турында сорады бит. Ә әни кеше өчен, күпме вакыт узса да, үз баласы матур, төз буйлы һәм яшь булып кала. Бу дөньяда башка кешеләр күзе белән карарга өйрән, шул вакытта башкаларны яхшырак аңлый башларсың, – диде бабай.

Ышаныч

Мәдрәсәдәге шәкерт остазыннан:

– Кешеләрнең ышанычлыларын танырга өйрәтсәгезче, хәзрәт? – дип сорый.

– Башта мин сине нинди кешеләрдән сак булырга тиешлеген өйрәтермен, – дигән остаз, – тын гына йөрүчеләрне, һәрнәрсәгә дә “әйе” дип торучылардан саклан. Кемдер сезгә баш игән кебек була, кемдер сезне кочаклап, сезгә мактауларны күп әйтә, шулардан беренче чиратта ерак йөр!

– Ничек алай була соң ул? – ди шәкерт, – аңлатып бирегезче, хәзрәт.

– Әүвәл менә шул кешеләр сиңа хыянәт итәчәк, – дип әйтә остаз.

– Алай булгач, миңа кемгә ышанырга соң, хәзрәт? – дип сорый шәкерт.

– Синең белән гади генә сөйләшкән, дөреслек нинди генә булса да, сиңа һәрчак турысын әйтә торганнарга. Менә шундыйлар – сиңа беренче булып ярдәм итәргә ашыгучылар!

Нияз БИШБАЛТА туплады.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

17 март – «Санаулы кичләр» (А.Володин).
18 март – 12.00 – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров). 18.00 – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
19 март – 12.00 – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров). 19.00 – «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф.Бүләков).
21 март – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
22 март – «Сәфәр» (А.Шакиров).
23 март – «Өйләнәм. tat» (И.Зәйниев).
24 март – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

18,19 март – «Евгений Онегин» (П.Чайковский).
23 март – «Турандот» (Дж. Пуччини).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

17 март – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
18 март – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
19 март – «Кияүләр» (Х.Вахит).
21 март – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (А.Бик-Булатов, Й.Миңнуллина, Э.Дусаева, М.Гафурова).
22 март – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
23 март – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
24 март – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

17 март – «Алтынч[ае]ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
18 март – «Арыну» (Т.Кулов, А.Әхмәдиев).
19 март – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).
21 март – «Рөстәм маҗаралары» (аталы-уллы Гадел һәм Рөстәм Кутуйлар әсәре, А.Әхмәдиев инсценировкасы).
22 март – «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла).
23 март – «Гөлчәчәк» (татар халык әкиятенә нигезләнгән).
24 март – «Йосыф» (Кол Гали).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

17 март – 11.00 – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). 19.00 – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
18 март – Зур залда – «Гусенок» (Н.Гернет). Кече залда – «Йолдыз тапкан кыз» (Ф.Яруллин).
19 март – Зур залда – «Царевна-лягушка» (Н.Гернет». Кече залда – «Җырла, Курай!.. Уйна, Шомбай!» (С.Дорожко, Р.Зәйдулла тәрҗемәсе).
21 март – «Бобровый пруд».
22 март – «Shurale: яңа фантазия» (Ф.Яруллин).
23 март – «Сны Диснея» (И.Зәйниев).
24 март – 11.00 – «Сны Диснея» (И.Зәйниев). 18.30 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

17 март – Джаз кичәсе.
18 март – Җырчы-авторларның үз җырларыннан концерт.
19 март – 11.00 – Балалар өчен концерт. 18.30 – Җырчы Эльмира Кәлимуллина концерты.
24 март – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

17 март – La Primavera оркестрының борынгы музыка уен коралларына багышланган концерты.
18 март – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрына кушылып органда Жан-Пьер Стайверс уйный. Дирижер – Иван Великанов.
19 март – Балалар өчен «Lego music» дип исемләнгән интерактив уен.
20 март – La Primavera камера оркестры концерты.

Зыянлы түгел, файдалы

Соңгы вакытта, сөт һәм аңардан әзерләнгән ризыклар организм өчен зарарлы, дип кешеләрне куркытучылар күбәйде. Ә менә галимнәрнең халыкара командасы, шул исәптән Бөекбританиядәге Ридинг университетының абруйлы галимнәре, сөт продукциясе кеше сәламәтлегенә бернинди дә зыян китерми, дип раслый. Профессор Йен Гивенс җитәкчелегендә үткән тикшеренүдә төрле илләрдән миллионга якын кеше катнашкан. Киресенчә, сөт ризыклары йөрәк өянәге куркынычын киметергә сәләтле икән. Галимнәр фикеренчә, майлы сөт һәм сыр сәламәтлек өчен файдалы, әмма табибләр шуның киресен дәлилләмәкче була. Нәтиҗәдә азык-төлек сәнәгате майсызландырылган сөт ризыкларын көннән-көн күбрәк җитештерә. Гивенс әйтүенчә, майсызландырылган ризык кына кулланганда, сөякләргә зыян килә һәм остеопороз башлану ихтималы арта. Сәламәтлек саклау оешмасы һаман куркытканга, яшьләр сөтне аз эчә һәм организмнарын бик кирәкле кальцийдан мәхрүм итә. Галимнәрнең фикере катгый: майлы сөт ризыкларын һичшиксез кулланырга кирәк!

(“Die Presse”).

Уксыз сәгать

Иң беренче кесә сәгате 1524 елда уйлап табылган, әмма 1675 елда гына Гюйгенс аңа патент алган. Бик озак вакыт буе әлеге механизмнарның бер генә угы булган – сәгатьне күрсәткәч, шул җитә, дип саналган. Минутны күрсәтә торган ук XIX гасырда, секундны күрсәтә торганы XIX гасыр азагы - XX гасыр башында гына барлыкка килгән һәм баштарак беркемгә дә кирәкмәс әйбер булып тоелган. Иң беренче механик сәгатьләр әллә ни төгәл дә булмаган.

(“Лента.ру”).

Ерткыч кош

Бик күпләр, рәхимсезлек бары тик кешегә генә хас, хайваннар исә зарурлык туганга гына җан кыя, дип ышана. Лачыннар семьялыгына кергән ерткыч кош – Гуадалупе каракарасы әлеге фикернең ялгышлыгына дәлил булып тора. Мексиканың Гуадалупе утравында яшәгән каракара хәтта тамагы тук вакытта да, тик торганда да башка хайваннарны үтерә торган булган. Аның иң яраткан шөгыле – нәни кәҗә бәтиләрен берсе артыннан берсен чукып үтерү. Чирле һәм зәгыйфьләнгән үз кардәшләренең дә җанын кыюдан тайчанмаган бу ерткыч. Үзен исә фермерлар кырып бетергән. Иң соңгы каракараны 1903 елда күргәннәр.

(“TravelAsk).

Бетле йогурт

